www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 40 (1456) 13 октябрь 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga

5

1930 елның җәендә Башкортстанның Чишмә районына ял итәргә баргач, Муса Җәлил Кара Якуп авылында яшь җырчы Зәйтүнә Илбаева белән таныша һәм 1942 елның гыйнварына кадәр аңа хатлар яза.

8-9

Явыз Иван беренче һөҗүмен 1545 елда башлап, Казан каласын 1552 елда яулап алуга ирешә, ә Емельян Пугачев аңа өч сәгать эчендә бәреп керә.

12-13

Башкорт мөтәгалимнәре элеккеге Минзәлә өязе җирләренә борын сузып маташса да, Уфа белән Казан арасында XIX гасырга кадәр сыңар гына башкорт волосте да булмаган.



Алтын көз – җанның иң ямьле, Иң гамьле мәледер ул!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- 7 октябрьдә яңадан Палестина-Израиль сугышы башланды.
- Үзбәкстан җырчысы, «Ялла» төркеменең сәнгать җитәкчесе Фәррух Закировка «Татарстанның халык артисты» исеме бирелде.
- Казан каласының Татарстан урамындагы 16/78 номерлы йорт диварына атаклы җырчыбыз Зифа Басыйрова хөрмәтенә мемориал такта куелды.
- Татарстанда 2024 елда Сочида узачак Бөтендөнья яшьләр фестиваленә волонтерлар сайлап алу башланды.
- Илкүләм «Демография» милли проекты кысаларында авыл җирлегендә яшәүче 45 меңләп өлкән яшьтәге татарстанлы диспансерлаштыру үтте, 5 меңгә якын кеше тирәнтен тикшерүгә җибәрелде.
- Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театрында «театр дәресе» форматында спектакльләр циклы башланды.
- Уфаның Киров районында Дагестанның халык шагыйре Рәсүл Гамзатов исемендәге урам барлыкка киләчәк.
- Санкт-Петербургта Лев Гумилевның тормышы һәм иҗатына багышланган күргәзмә оештырылды.
- Мәскәү Татар мәдәнияте үзәгендә «Татарстан музыкаль театры хәзинәсеннән» XXI «Багышлау» татар хор музыкасы фестивале узды.
- Истанбул халыкара күргәзмәсендә Казанның туристлык мөмкинлекләре тәкъдим ителде.
- Казан хореография училищесында күренекле балерина, педагог, РСФСРның, Татарстан һәм Башкортстан Республикаларының халык артисты Нинель Юлтыева хөрмәтенә мемориаль такта куелды.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

13 октябрь – шагыйрь Хәбиб Шәрифулла улы Исхакый (Исхаков)ның тууына 140 ел (1883-1913);

– рәссам, Татарстан Республикасының халык рәссамы, ТР ның атказанган сәнгать эшлеклесе Мөдәррис Мөхетдин улы Минһаҗевка 70 яшь (1953).

16 октябрь – язучы, журналист Әсрар Галиевнең тууына 85 ел (1938-1998).

17 октябрь – актёр, ТАССРның атказанган артисты Фәридун Ибраһим улы Юнысовның тууына 110 ел (1913–1978).

СЫНАМЫШЛАР

● Покрауда (14 октябрь) җил көнчыгыштан булса, кышка суык китерер.

● Покрауда кар күренсә, кырык көннән кар ятар.

● Покраугa кадәр кар төшсә, көз озын булыр.

● Покрау үтте – кыш җитте.

● Кара көзнең кары ятмас.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **6 сәгать 10 минутта** чыкты, һәм ул **16 сәгать 51 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **10 сәгать 41 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **31 минутка** кыскарачак һәм киләсе җомгада, ягъни **20 октябрьдә 10 сәгать 10 минут** тәшкил итәчәк.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Октябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, яңа айдан айның беренче чирегенә кадәр **(14-22 октябрь)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1445 ЕЛ

Бүген рабигүл әүвәл аеның 28 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

АЕРЫЛЫШУ ТАРИХЛАРЫ

ЗАГС белгечләре, юристлар, психологларга үз практикаларында аерылышучы парлар белән күп эшләргә туры килә. Алар «Челнинские известия»га иң моңсу һәм гадәти булмаган аерылышу тарихларын сөйләгән.

Кул күтәрү һәм көнчелек

«Бер туй ЗАГСтан соң ук бозылган: рәсми өлештән соң, яшь пар чишмәгә барган, һәм анда кияү, дөресрәге, инде ир, ялгыш кына кәләшнең күлмәгенең очына баскан. Кәләш тавыш куптарган, ә кияү аңа китереп суккан. Шуның белән гаилә таркалган, кунаклар кафега да барып өлгермәгән», – дип сөйләде психолог Нелли Матросова.

Белгеч фикеренчә, сәбәбе – мәхәббәт һәм тәрбия булмау. Алар яратышып түгел, ә башка сәбәпләр аркасында өйләнешкән. Әйе, туй – стресслы чара. Ләкин ике кеше бер-берсен яратышып өйләнешә икән, стресс андый роль уйнамый.

«Хәзер күп кенә яшь парлар бергә яшәп карарга тели, әмма мин үз балаларым өчен моны теләмәс идем. Экәрсез хисләр булса, бу кичектерү нәрсәгә кирәк?» – ди психолог.

Икенче бер психолог Наталья Аблизина практикасындагы очрак аның хезмәттәшенең карашына каршы килә.

«30 яшьлек ир туйдан соң 2 ай үткәч аерылыша, бөтен гаепне хатынына сылтый. Ул гаиләдә бердәнбер бала булган, иркәләп үстерелгән һәм һәрнәрсәгә бәйләнгән: өстәл әйбәт әзерләнмәгән, савыт-саба дөрес юылмаган, күлмәк яхшы үтүкләнмәгән. Шулай ук ул хатынын билгеле бер позада: аны кочаклап, аягын куеп йокларга мәҗбүр иткән. Әгәр дә йоклап киткәч борылып ятса, ул аңа дәшмичә йөреп, бойкотлар оештырган»,– дип мисал китерә психолог Н.Аблизина.

Шушы очрак уңаеннан белгеч психоанализ классигы Франсуаза Дольтоның «Нормаль аерылышу начар никахтан яхшырак» дигән сүзләрен искә төшерә.

«Партнердан бик күп нәрсә өмет иткән очраклар була. Ләкин ир белән хатынның бер-берсен бөтенләй белмәүләре бик тиз ачыклана. Мондый хәл кешенең гаиләне аңа күп нәрсә тиеш булган әйбер итеп кабул итүе очрагында еш күзәтелә. Шул ук вакытта ул үзе дә каршы якка тиеш булуы турында уйламый».

Менә Чаллы ЗАГСында эшләгән гаилә психологы Люция Чукмаровадан алынган тарих.

«Иртән кабинетка бер кыз бәреп керде һәм ишек төбендә үк: «Ничек аерылышырга?» – дип сорады». Ачыкланганча, аларның туйлары кичә генә булган, алар өйдә бәйрәм иткәннәр, ире эчкән, сүзләргә бәйләнә башлаган һәм бар кеше алдында хатынын таба белән кыйнаган. Аларны, законда күрсәтелгәнчә, 1 айдан соң аердылар, – дип уртаклашты психолог.

– Минем кандидатлык диссертациям 90 нчы еллардагы гаилә мөнәсәбәтләре динамикасына багышлана. ЗАГС алып барган аерылышуларның сәбәпләре статистикасында ул вакытта беренче урында «характерлар белән туры килмәү» дигән сүзтезмә булган, ә моның артында алкоголизм, аралаша алмау яшеренгән. Яңа өйләнешкән кайбер парлар, хәтта үз партнерларының характер сыйфатларын күреп тә, бу хәлне җиңелчә генә җиңә булуын, яңадан тәрбияли алачакларын уйлый».

Шундый нигездә булган аерылышу тарихлары журналистика практикасында да очрый, алар редакциягә криминаль белешмәләрдән килә. Менә шуларның берсе.

42 яшьлек балалар бакчасы тәрбиячесе булган кызларының туган көненә әти-әнисе аның хыялын – будуар өстәлен бүләк итә. Әтисе аны җыеп, йокы бүлмәсенә урнаштыра. Хатын хушбуйлар, кремнарын шул өстәлгә тезеп куя. Парфюмерия кичкә кадәр генә тора ала. Хатынның шофер ире, бүләкне күргәч: «Син сөяркәң өчен марафет ясаячаксыңмы?» – дип тузына. Чүкеч алып, өстәлне ватып бетерә, флаконнар тәрәзәдән оча. Талаш шаһитлары, 2 мәктәп баласы, әбиләре белән бабайларын чакырып китерәләр. Алар килгәч, кияүләренә бер сүз дә әйтмиләр.

Хатын-кыз ватыкларны җыештырып тормый, әйберләрен җыя да әти-әнисе белән китеп бара. Ире шалтыратмый, гафу үтенми, күрсәң, үзен дөрес дип саный. Хатын аерылышу өчен гариза яза.

Тую һәм читләшү

«60 яшьлек бай ир-ат картаеп баручы хатынының исеннән чиркана һәм аның янында тора алмый башлый. Күчемсез милекне бүлгәндә хатынының барлык шартларына да риза була. Хатын бик нык елый», – дип сөйләде Чаллы юристы Людмила Головина.

Җенси канәгатьсезлек аркасында ирләр генә аерылышмый. Юрист сөйләвенчә, бер хатын, бай гаиләсен ташлап, яшь сөяркәсе янына китә, аның белән ул традицион булмаган җенси мөнәсәбәтләр белән шөгыльләнгән.

Көнчелек башка гаиләдә аерылышуга сәбәп була. Ире 25 яшьлек хатынына үзенә ошаган кием кияргә, чәчләрен кисәргә, косметика кулланырга рөхсәт итми. Син болай да бик матур, ди. Аерылышуга китергән соңгы тамчы – хатынның иртә белән душтан соң сөлгегә уранган килеш кенә бер минутка балконга чыгып, ниндидер әйберне алып керүе була. Аерылышу процессы озакка сузыла, хәзер икесе дә ялгыз.

Үз практикасына йомгак ясап, юрист аерылышуның ике сәбәбе барлыгын билгеләп үтте: бу – җенси канәгатьсезлек һәм ир-атның табыш китерүче булырак сәләтсезлеге.

Курьезлар һәм татулашулар

Аерылышу тарихлары арасыннан безгә дә кызыклы очраклар эләкте. Ир белән хатын 4 ел яши. Ире берни эшли белми һәм өйдәге бар нәрсәне скотч ярдәмендә ремонтлый. Фатирлары иске була һәм залдагы форточка җимерелеп төшәргә тора. Ул аны да скотч белән урагач, хатыны: «Җитәр!» – дип, аерылыша.

Шәһәрнең ЗАГС идарәсендә аерылышулар буенча баш белгеч Татьяна Милованович фикеренчә, соңгы елларда никахка мөнәсәбәт кискен үзгәрде, кешеләр аңа җиңелрәк карый башлады, туйны гына түгел, аерылышуны да шау-шулы һәм күңелле итеп билгеләп үтәргә мөмкиннәр. Аерылышу турында таныклык алган көнне ЗАГСка дуслары белән киләләр, дус кызлары аерылышкан хатынга, «Яңа тормыш белән!» дип, чәчәкләр бүләк итә.

Татьяна Милованович Чаллы ЗАГСында татулашу булган очракны да искә төшерде.

Чит ил кешесе Чаллылы хатыны белән өйләнешеп 5 ел яши, бу еллар дәвамында ул аны үзенең туган ягына, Германиягә күченергә чакыра. Әмма хатыны моңа каршы була. Ирнең сабырлыгы бетә, һәм ул аерылышу өчен гариза бирә. Билгеләнгән көнне ул ЗАГСка беренче булып килә, бик нык борчыла. Хатын белешмәне соңрак ала. Алар коридорга чыгалар, бергә утырып нәрсәдер сөйләшәләр.

«Без аларны саубуллашалар дип уйладык. Әмма пар көтмәгәндә кулга-кул тотышып һәм, елмаеп, никахны теркәү турында гариза бирү өчен кабинетка керде»,– дип сөйләде Т.Милованович.

«Челнинские известия» газетасы үткәргән сораштыру буенча, өйләнешкән парлар арасыннан холыклары туры килмәгәнгә аерышучылар – 30, акча җитмәгәнгә аерылып китүчеләр – 18,5, парларның берсе хыянәт иткәнгә күрә гаилә җимерүчеләр – 16, 3, ирләре яки хатыннары эчкәнгә яки наркотик белән мавыкканга күрә аерылучылар – 15,2, туганнары гаилә тормышына кысылганга күрә аерылып китүчеләр – 12,5, яшәргә торак урын булдыра алмаганга күрә аерылышучылар – 6,5, балалары булмаганны сәбәп итеп гаилә таркатучылар 1 процент тәшкил итә икән.

«Челнинские известия» сайтыннан тәрҗемә ителде.

Ләлә ГӘЙФЕТДИНОВА.

«Безнең җыр» лабораториясенең яңа дулкыны

«Калеб» яңа буын җыены 25 сентябрьдә «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә «Безнең җыр» лабораториясенең икенче сезонын ачып җибәрде. Беренче тапкыр ул 2019-2021 елларда узган иде. Проект Казан хакимияте һәм Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре Комиссиясе ярдәме белән уздырыла. Максаты – сәнгатьнең төрле өлкәләрендә эшләүче яшьләргә уртак иҗади мохит булдыру, шагыйрь, композитор һәм җырчыларны үзара таныштыру, яңа әсәрләр иҗат итү һәм милли җыр фондын тулыландыру.

«Безнең җыр» лабораториясенең идея авторы, «Калеб» җыены җитәкчесе, Казан башкарма комитеты җитәкчесенең социаль өлкә мәсьәләләре буенча урынбасары Гүзәл Сәгыйтова лабораториядә катнашучы иҗатчыларны сәламләде һәм үз фикерләрен җиткерде: «Җыр конкурслары, фестивальләре аз түгел. «Безнең җыр»ның яңа сезонын үткәрү никадәр актуаль соң? Бу сорау минем өчен иң мөһиме иде. Ләкин соңгы ярты елда миңа узган лабораториянең катнашучылары бик еш мөрәҗәгать итте. Алар шушы иҗади эксперимент атмосферасын бик сагынган. Шуңа да лабораториянең икенче сезоны булырга тиеш дигән фикергә килдек. Өстәвенә, «Безнең җыр» уникальлеген югалтмады. Күпкенә фестивальләрдән аермалы буларак, бездә инде язылган җырларны башкармыйлар, лаборатория барышында өр-яңа җырлар иҗат ителә».

Лаборатория шартлары буенча шагыйрь, композитор һәм җырчыдан торган 16 команда ярты ел дәвамында 16 яңа җыр иҗат итәргә тиеш. Командаларны билгеләү – очрашуның төп интригасы иде. Өчлекләр составын һәм җырның юнәлешен шобага салып билгеләделәр. Әйтик, бер төркемдә җырчы Илүсә Хуҗина, шагыйрә Луиза Янсуар, композитор Гөлнара Тимербулатова, икенче төркемдә җырчы Эльмира Кәлимуллина, шагыйрә Эльвира Һадиева, композитор Ильяс Камал, өченчесендә җырчы Алинә Кәримова, шагыйрә Йолдыз Миңнуллина, композитор Эльмир Низамовлар бергәләп иҗат итәчәк. Шундый төркемнәрнең саны -16.

Композитор Э.Низамов болай ди: «Узган «Безнең җыр» лабораториясендә матур җырлар гына түгел, иҗади дуслыклар да туды. Ә бу лабораториянең иң олы максаты иде. Быелгы шобага нәтиҗәләре белән мин бик канәгать. Йолдызны шагыйрь буларак та, кеше буларак та яратам. Ә Алинә Кәримова – әниемнең яраткан җырчыларының берсе. Димәк, шушы тандемда эшләп карау – язмыш булган».

16 команда да инде җыр язуга кереште. Проектның кураторы – Лилия Гәрәева сүзләренә караганда, лаборатория барышында туган җырларны тыңлап карау этабы ел азагына хәтле, проектның гала-концерты исә апрельгә планлаштырыла.

Эльмира СИРАҖИ.

Төркиядә яңа китап

Әнкарада Атайурт нәшриятында төрек телендә татар галимәсе Роза Корбанның «Идел-Урал зыялылары-2» исемле китап дөнья күрде. Бу китап – 2022 елда басылган «Идел-Урал зыялылары-1» китабының дәвамы. 290 битлек «Идел-Урал зыялылары-2» китабында татар зыялылары, татар тарихы, әдәбияты һәм мәдәнияте турында 21 мәкалә тупланган. Мәкаләләрдә татарларның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында уйланулар бар.

Татар зыялылары милләт язмышына ваемсыз булмаган, кулыннан килгәне хәтле милләткә хезмәт иткән. Репрессия елларында алар сөргенгә җибәрелгән, төрмәләргә ябылган, атып үтерелгән. Китапта репрессия корбаннары: язучы, тарихчы галим Газиз Гобәйдуллин; тарихчы Һади Атласи; шагыйрь, драматург, тарихчы, мөгаллим Фазыл Туйкин; XX йөз татар реалистик прозасының күренекле вәкиле, татар әдәбиятында тарихи роман жанрына нигез салучыларның берсе Мәхмүт Галәү; татар драматургиясе классигы, режиссер Кәрим Тинчурин; язучы, шагыйрь, әдәбият тарихчысы һәм тәнкыйтьчесе Гали Рәхим; язучы-прозаик, тәрҗемәче Садри Җәләл; язучы-прозаик, әдәбият һәм тел галиме, тарихчы, җәмәгать һәм сәясәт-дәүләт эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов; мәгърифәтче педагог, нәшир һәм язучы Фатих Кәрими; Колыма тоткыны, язучы Ибраһим Сәлахов; татар мәгарифенә нигез салучылар булып саналган педагог, Иж-Бубый мәдрәсәсе җитәкчеләренең берсе, дәреслекләр төзүче Габдулла Буби, дин һәм җәмәгать эшлеклесе, нәшир Габдулла Апанаев, сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе Йосыф Акчура һ.б. галимнәр һәм язучылар турында укырга мөмкин.

Шулай ук, татар әдәбиятында тарихи роман язучы беренче карлыгачлар Нурихан Фәттах һәм Мөсәгыйт Хәбибуллин; күренекле язучы-прозаик, милләтпәрвәр публицист Тәүфикъ Әйди, XX йөз татар әдәбияты классигы, Татарстанның халык язучысы, тел-әдәбият галиме Нәкый Исәнбәт, әдәбият галиме, педагог Хатыйп Миңнегулов турында да киң мәгълүмат бирелгән.

Татар шигърият дөньясының якты йолдызы Һади Такташ, Татарстанның халык



шагыйре Мөдәррис Әгъләмов, заманның көрәш ялкыны белән сугарылган милли рухлы шагыйрә Нәҗибә Сафина да төрек укучыларына тәүге мәртәбә тәкъдим ителде.

«Идел-Урал зыялылары-2» китабы 22 сентябрь-1 октябрь көннәрендә Төркиянең Маниса шәһәрендә узган 5 нче китап ярминкәсендә беренче тапкыр сатуга чыкты.

Депутатны наркотиклар белән тотканнар

Казанда полиция хезмәткәрләре Татарстанның Дәүләт Советы депутаты Рөстәм Хәсәновны кулга алган. Анда мефедрон наркотигы тапканнар. Бу хакта Mash Iptash телеграм-каналы хәбәр итә.

Депутатны 17 сентябрьдә, Беломорская урамында «Казаньоргсинтез» заводы янында тоткарлаганнар. Канал язуынча, ул закладка – наркотик сатучылар яшерен урынга куеп киткән наркотикны алганда кулга алганнар. Аны күзәтеп торганнар, закладкадан наркотикны алуга тоткарлаганар. Анда 1,88 грамм наркотик булган, бу – зур күләм булып санала. Закон буенча, Хәсәновны 12 елга төрмәгә утыртырга мөмкиннәр.

116.RU редакциясе депутат белән элемтәгә керә алмаган, аның телефоны сүнгән.

Рөстәм Хәсәнов – республика Дәүләт Советының социаль сәясәт комитеты әгъзасы. Элек ул «День добрых дел» хәйрия фонды директоры да булган. Бу оешма урамнарда сукбайларны ашаткан, инвалид балаларга реабилитация өчен җиһазлар сатып алган. Рөстәм Хәсәнов үзе Татарстандагы ярлылык турында борчылып сөйләгән була. Шулай ук «День добрых дел» фонды «Реставратор» фирмасына да ярдәм итеп торган. Әлеге фирма тарихи йортларны кабат торгызу белән шөгыльләнгән. Аерым алганда, Михляев йортына реставрация ясаган, Петропавлов соборы терәкләрен ныгыткан.

Әмма монда да кызыклы гына нюанс бар. «Реставратор» компаниясе депутатның үзенеке булган. 2021 елда ул банкрот булып таныла. Аның кредиторлары арасында «Ак Барс Банк» кебек мөһим оешмалар, хәтта салым инспекциясе дә булган. Барлыгы 19 оешма. Суд приставлары сайтындагы мәгълүматка караганда, хәзер Хәсәновның 25 млн сум бурычы бар.

ТР Дәүләт Советы сайты.

Дәүләт бүләкләре

Мәгариф өлкәсенә һәм югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә керткән казанышлары өчен Казан (Идел буе) федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге математика һәм механика институтындагы алгебра һәм математик логика буенча кафедра мөдире

Марат Мирза улы Арсланов

һәм филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Л.Н.Толстой мирасын өйрәнү буенча фәнни-мәгариф үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре

Марсель Хәернас улы Бакиров

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов Указы нигезендә «Дуслык» орденнары белән бүләкләнде.

Мәскәү татарлары Эчкенгә ярдәм итә

«Ак Барс» эшмәкәрләр клубы һәм Мәскәү татарлары автономиясе Курган өлкәсендә янгыннан зыян күрүчеләргә ярдәм җыюны дәвам итә. Бу хакта Мәскәү татарлары автономиясе хәбәр итә.

2023 елның маенда Курган өлкәсендә борынгы татар авылы – Йолдыз (Эчкен) тулысынча диярлек янып бетте. Янгын 220 дән артык йортны юк итте, 500 дән артык кеше урамда торып калды. Татар иҗтимагый оешмалары һәм мөфтиятләре бөтен көчен куеп әлеге татар авылын яңадан торгызырга ярдәм итә.

Бүгенге көндә йөздән артык йорт төзелә. Әмма бер мизгелдә бөтен милекләрен югалткан кешеләргә хәзер дә төзелеш материаллары, мебель, газ җиһазлары сатып алуда, су һәм җылылык белән тәэмин итүдә ярдәм кирәк. Һәркемнең ярдәме бик тә мөһим, диелә хәбәрдә.

Фаҗига өчен түрә җавап бирә

Тәтештә 22 февральдә куркыныч фаҗига булды. 10 яшьлек малай, мәктәптән кайтканда, ташландык урыннан уза һәм шундагы ачык канализация чокырына төшеп һәлак була.

Бу фаҗига өчен район башкарма комитетының җитәкчесе – хәзер инде элекке җитәкчесе, 51 яшьлек ир җавап бирәчәк. Ул бала үлеменә китергән битарафлыкта (Җинаять кодексының 293 нче маддәсе) гаепләнә.

Тикшерү фаразы буенча, түрә 2015 елдан бирле, торак йортлардан 20 метр гына ераклыкта гына элекке чистарту корылмалары булганын, анда люклар ачык икәнен белгән. «Шуңа да карамастан, ул хуҗасыз милекне хисапка алу буенча чаралар күрмәгән, коеларны имин хәлдә тотмаган һәм читтән кеше кермәсен өчен чаралар күрмәгән», – диелә тикшерү комитеты хәбәрендә.

Җинаять эше судка җибәрелгән.

1 нче биттә – Көзгә моңсулык.

Израиль-Палестина сугышлары тарихы

Израиль 2023 елның 7 октябрендә, ХАМАС («Ислам каршылык хәрәкәте») аңа һөҗүм иткәннән соң, Газа секторындагы ХАМАС хәрәкәте белән сугыш башлавы турында игълан итте. Искәртеп үтик, Палестинаның ХАМАС хәрәкәтен Израиль, Канада, АКШ, Япония, Европа Берлеге, Америка дәүләтләре оешмасы һәм башка илләр террор оешмасы дип таныган. Палестина белән Израиль арасындагы бәрелешнең күпьеллык тарихы бар һәм ул гарәп-Израиль конфликтының бер өлеше булып тора.

Якын Көнчыгыш конфликты турында кыскача тарихи аңлатма тәкъдим итәбез.

Палестинаның яһүдләр һәм гарәпләр өчен әһәмияте

Израиль җире яһүд халкы өчен изге язмалар заманыннан бирле изге урын санала. Бу – якынча безнең эрага кадәр ике мең еллар. Анда беренче кабиләләр якынча б. э. к. 1200 нче елларда барлыкка килә башлаган. Безнең эрага кадәр VIII гасырдан башлап Израиль территориясе эзлекле рәвештә Ассирия, Вавилон, фарсы Ахеменидлар державасы, Македония, Рим хакимлегендә була. Ул чорда яһүдләрнең күпчелеге тарихи ватанын ташлап киткән.

638 елда хәлиф Гомәр җитәкчелегендәге гарәпләр Иерусалимны ала. 640 елга бөтен Палестина гарәпләр тарафыннан яулап алына һәм Гарәп хәлифәлеге составына кертелә. Палестинада этник яһүдләр үзгә, халык сакланып калса да, ул вакытта бөтенләй диярлек юкка чыга.

XVI-XIX гасырларда Израиль Госманлы империясе контролендә була. 1880 елга Палестина халкы 450 мең кеше санала; моңа Иерусалимда яшәгән һәм бу илнең яртысын тәшкил иткән 24 мең яһүд тә кергән.

Яһүдләрнең XIX гасырда Палестинага кайтуы

Дәверләр дәвамында яһүдләр милли һәм дини әзәрлекләүләр аркасында Палестина һәм Израиль территориясендәге яшәү урыннарын калдырып китәргә мәҗбүр булганнар. Төрле тарихи чорларда депортациягә бәйле рәвештә яһүдләр өчен сыену урыны алу омтылышы сионизм (яһүд милли хәрәкәте, үз максаты итеп яһүд халкын аның тарихи туган җире Эрец Исраэльдә (Израиль җире) берләштерүне һәм торгызуны куя. – ред) хәрәкәте барлыкка килү һәм XX гасыр урталарында Израиль дәүләте булдыру өчен стимул булып тора.

Яһүд халкының Израильгә кайтуының беренче зур дулкынына «Беренче алия» исеме бирелә. Шул вакытта күченүчеләр халыкның тарихи җирләргә кайтарылуын башлап җибәрә. «Икенче алия» 1904-1914 елларда уздырыла. Ул вакытта 40 мең яһүд Палестинада урнаша. Тагын 40 мең яһүд 1919-1923 елларда күченеп килә. Бу яһүдләрнең туган илләренә массакүләм күченеп кайтуының «Өченче алия»се була. Шул вакытта ук гарәп протестлары башлана, алар Палестина фетнәләре китереп чыгара.

1920 елның 4 апрелендә Муса пәйгамбәр хөрмәтенә бәйрәм яһүдләргә каршы бәрелешләргә әверелә. Бу көнне халык Иерусалимның яһүд кварталына таба китә. Шәһәрдә фатирларда торган Британия гаскәрләре чуалышлар башланганчы берничә көн алдан аннан чыгарылган була. Чуалышлар дүрт көн дәвам итә, нәтиҗәдә биш яһүд үтерелә һәм 200гә якын кеше яралана. Ул чорда Бөекбритания Палестина белән идарә итү мандаты ала һәм яһүд иммиграциясен чикли. Ул вакытта Палестинада күбесенчә мөселман гарәпләр яши. Әмма иң зур шәһәр – Иерусалимда күбесенчә яһүдләр көн күргән.

Икенче бөтендөнья сугышы вакытындагы Холокост – фашистик Германия тарафыннан яһүдләрне эзәрлекләү сәясәте вакытында Палестинага иммиграция тыюын урап узу өчен «Моссад ле-Алия бет» дигән яшерен оешма оештырыла.

Икенче бөтендөнья сугышы тәмамланганнан соң Палестина территориясендә яһүд халкының 33 проценты яши.

1947 елда Британия хөкүмәте Палестина мандатыннан баш тартырга теләвен белдерә, моны гарәпләр һәм яһүдләр арасындагы конфликтны хәл итә алмавы белән дәлилли.

Израиль дәүләтен төзү

Берләшкән милләтләр оешмасы (ООН) Генераль Ассамблеясы 1947 елның 29 ноябрендә Палестинаны гарәп һәм яһүд дәүләте (Израиль) итеп бүлү турында резолюция кабул итә. 1948 елның 14 маенда Израильнең бәйсезлек декларациясенә кул куела. Шул вакытта яһүд дәүләте игълан ителә.

Израильне беренче булып АКШ таный. 1949 елның 11 маенда Дәүләт ООН әгъзасы буларак танyла.

Моңа кадәр бер ел элек, 1948 елда Израиль дәүләте игълан ителгәнче, гарәп-Израиль сугышы (1947-1949) башлана. ООН Палестинаны гарәпләргә һәм яһүдиләргә тигез итеп бүлү турында карар кабул иткәннән соң, миллионга якын яһүд гарәп илләреннән Израильгә куыла.

Сугыш вакытында массакүләм югалтулар була. Израильнең 777 кешесе үтерелә һәм 2586 кешесе яралана. Гарәп армияләре 15 меңгә якын кеше югалта. Гарәпләр башта ук Израиль дәүләтен булдыруга каршы була. Яһүдләр исә инде күп еллар элек югалткан тарихи ватанын кире кайтарырга омтыла.

1950 елның 23 гыйнварында Кнессет (Израиль парламенты) Иерусалимны Израиль дәүләте башкаласы дип игълан итә, гәрчә ООН карары буенча Иерусалим гарәпләр шәһәре дә, яһүдләр шәһәре дип тә игълан ителгән була. Моның сәбәбе – Иерусалимдә мөселманнар өчен изге Әл-Акса шәһәре дә, яһүдиләр өчен изге урыннар да бар.

Гарәп-Израиль сугышы (1948-1949) барышында яһүдиләр Палестина территориясенең 77 процентын басып ала. Яһүдләргә каршы бу сугышта шулай ук Мисыр, Сирия, Ливан, Согуд Гарәбстаны, Гыйрак һәм Йемен катнаша.

1967 елдан, Алты көнлек сугыш нәтиҗәсендә, Израиль Иерусалимның бөтен территориясен контрольдә тота башлый. Илнең контроле астында шулай ук Синай ярымутравы, Иордан елгасының көнбатыш ягы, Көнчыгыш Иерусалим, Голан калкулыклары, шулай ук Мисыр контролендә булган Газа секторы кала.

1973 елның 6-25 октябреннән гарәп-Израиль сугышы («Война судного дня») башлана. Мисыр һәм Сирия, Алты көнлек сугыш вакытында югалтылган гарәп территорияләрен кире кайтару өчен, Израильгә каршы чыга. Ул ООН Иминлек Советы хәрби хәрәкәтләрне туктату турында резолюция кабул иткәннән соң тәмамлана.



Газа Секторы (Газзә сызыгы, Сектор Газа) нәрсә ул?

Газа секторы – Урта диңгез ярындагы территория. Палестина Милли администрациясе составында, халык саны буенча иң зур шәһәр. Анда 2017 елга 590 мең кеше исәпләнгән. Ул Израиль белән көнчыгышта һәм төньякта чиктәш. Бу чик буенда контроль-үтү пунктлары белән аергыч койма бар. Мисырдан көньяк-көнбатышта бетон дивар белән аерылган. Газа секторының озынлыгы якынча 54 километр тәшкил итә, киңлеге – 6-12 километр.

360 квадрат километр мәйданда ике миллионнан артык кеше яши: нигездә 1947-1949 еллардагы гарәп-Израиль сугышы вакытында Израиль территориясеннән киткән Палестина качаклары.

Палестина һәм Израильнең хәзерге конфликтлары

1993 елның сентябрендә, яшерен сөйләшүләр нәтиҗәсендә, АКШ башкаласы Вашингтонда Израиль һәм Палестинаны азат итү оешмасы арасында конфликтны җайга салу өчен ике яклы килешү имзалана. Ослодагы килешүләр нәтиҗәсендә Иордан елгасының көнбатыш ярында һәм Газа секторында Палестина милли администрациясе (ПНА) оештырыла.

1995 елның 28 сентябрендә Вашингтонда «палестинлылар һәм Израиль Дәүләте арасында Иордан елгасының көнбатыш ярында һәм Газа секторында Вакытлыча килешүләр» имзалана. Документ вакытлыча характерда була һәм Палестина-Израиль конфликтыны тулысынча хәл итүне күздә тотмый. Ул Палестина милли администрациясе (ПНА) булдыруга китерә.

2000 елдан Иордан елгасының көнбатыш ярында һәм Газа секторында Палестина гарәпләренең Израиль хакимиятенә каршы кораллы күтәрелешләре башлана. Территорияләр арасындагы конфликт көчәйгәннән соң, Израиль 2006 елдан Газа секторында хәрби операцияләр үткәрә башлый.

2007 елда ХАМАС (Газа секторында идарә итүче сәяси партия) Палестина милли администрациясенә каршы күтәрелеш оештыра. Газа секторы 1967 елдан 2005 елга кадәр Израиль контролендә була. Иерусалим Палестина милли администрациясеннән (ПНА) мөстәкыйль рәвештә аерылып чыга.

Яклар 2014 елдан бирле бер-берсенә һөҗүм итеп килә. Палестина Израильгә ракета һөҗүмнәре оештыра, ә Израиль масштаблы хәрби операцияләр үткәрә. Хәзерге вакытта ХАМАС һәм Израиль арасында бәрелешләр тарихи территория өчен бара.

URA.RU
Евгений ДЮМИН
язмасыннан тәрҗемә.
intertat.tatar.

Җәлилне әсир иткән Дим кызы

Бу хакта билгеле крайны өйрәнүче Юрий Узиков яза, әлеге истәлек Башкортстанның байтак энциклопедик китапларына, хәтта Уфа буйлап сәяхәт белешмәләренә дә кертелгән. Мәшһүр шагыйрь, патриот Муса Җәлил күп тапкырлар Уфада, Башкортстанда була. Һәр килүендә ул башкорт әдәбияты, музыкасы, театры, халык иҗаты белән яхшырак танышу өчен файдаланырга тырыша.

1930 елның 30 июнендә Башкортстанның халык шагыйре Сәйфи Кудашка язган хатында ул болай ди: «Мин җәйне Уфада уздырырга булдым. Уфаны бик мактыйлар – суы тәмле, табигате матур, кызлары сөйкемле, диләр.

Бөтен Уралны әйләнеп чыккач, мин Абдулла авылында тукталырга, кымыз эчәргә, арыган тәнемне ял иттерергә телим. Бу сәяхәттә мин Уфа җәмәгатьчелеге, бигрәк тә әдәбиятчылар белән якынлашырга уйлыйм. Сез мине «Октябрь» журналында хезмәттәшлек итәргә чакырдыгыз. Һәм менә бу сәяхәт мине Уфа белән якынайтачак, дип уйлыйм. Әгәр дә мин килгәч, Сез анда булсагыз, яхшы булыр иде. Күп нәрсәләр турында сөйләшер идек».

Хатның фотокопиясе Казанда Муса Җәлилгә багышланган фото-альбомнарның берсендә басылып чыга.

Ул җәйдә шагыйрь Абдуллада түгел, ә Кара Якуп авылында ял итә.

«1930 елда без Башкортстанның Чишмә районы Кара Якуп ял йортында очрашырга килештек, – дип искә ала татар композиторы Җәүдәт Фәйзи. – Ай буе бергә булдык. Бергә урманнар буйладык, кич биергә йөрдек. Ләкин иң яраткан шөгыле – әдәби-музыкаль кичәләр оештыру. Клубта пианино бар. Мин, кайвакыт, уйныйм, Җәлил җырлый, ә яшьләр безнең җырны күтәреп ала. Муса еш кына үзенең яраткан җырларын җырлый: «Күгәрчен», «Әсилә-Вәсилә».

Бу кичәләрдә мавыгып катнашучылар арасында соңрак Башкорт АССРның атказанган артисты булачак Зәйтүнә Илбаева да катнаша.

«Кара Якупта ял иткәндә мин Җәлил белән таныштым. Бу 1930 елда булды, – дип искә ала Зәйтүнә Илбаева. – Ул ябык, уртача буйлы, теремек, сөйләм осталыгы белән аерылып тора иде...»

1933 елда Зәйтүнә Илбаева Мәскәү консерваториясенә укырга керә. Анда аңа Муса белән кабат очрашырга туры килә. Аларны татар композиторларының Җәлил сүзләренә язылган җырларын җырлавы якынайта.

1936 елның июнендә Муса Җәлил янә Башкортстанга «Йоматау» шифаханәсенә килә. Ул елны анда артистлар Әмин Зөбәеров, Галимҗан Карамышев, Хаҗи Бохарский, шагыйрь Хәй Мөхәммәтьяров һәм җырчы Зәйтүнә Илбаева ял итә. Һәм менә шифаханә буйлап хәбәр тарала: «Муса Җәлил килгән!»

Шагыйрь һәм Мәскәү консерваториясен тәмамлаучы яшь җырчы яхшы танышлар кебек җылы очраша. Зәйтүнә Илбаеваның истәлекләреннән күренүенчә, Җәлил «Йоматау»да ял иткәндә дә шигырьләр язуын дәвам иткән. Монда ял итүчеләр алдында ул үзенең «Дим кызы» дигән яңа шигырен укый.

«Безгә бу шигырь бик ошады, ул Зәйтүнәгә карата җылы хисләрдән тора», – дип яза Октябрьский шәһәреннән Хәлил Маннан. – Без барыбыз да бергәләп кул чаптык».

Соңрак шигырь «Зәйтүнәгә» дип атала башлый. Татарча текстын табу бәхетенә ирешмәдек, ә русчасы болай:

«Девушка с Демы! Пусть мы
расстались,
Верь, что любовь моя глубока.
Помни о ней, живи, не печалясь,
Как голубая Дема-река».

Рафаэль Мостафин «Муса Җәлил» китабында шагыйрьнең башкорт актрисасы Зәйтүнә Илбаева белән очрашуы турында искә ала. «Йоматау»да алар еш кына яңа көнкүреш, гаилә, коммунизм чорында мәхәббәт нинди булырга тиешлеге турында бәхәсләшә. Җәлил Мәскәүдә калган икътисад техникумын тәмамлаган кәләше Әминә Сәйфуллинаны сагына. Ул аңа бик еш хатлар яза, ә башкалага кайткач, аңа өйләнә.

● Муса Җәлил белән Әминә Сәйфуллина, кавышкач.

● Җәлилне гашыйк иткән «Дим кызы» Зәйтүнә Илбаева.

Муса Җәлилнең хатлары Зәйтүнә Илбаеваның гаилә архивында саклана. 1962 елда ул «Агыйдел» журналы редакциясенә дүрт хат тапшыра, алар басылып чыга. Аларның берсен Р.Мостафин үзенең китабында урыс теленә тәрҗемә итеп китерә. Хәтта шагыйрь элек башланган бәхәсне дәвам итә, мәхәббәт, гаилә турында фикерләрен үстерә.

Муса Җәлил хыялланган бәхетле гаиләсен төзи. Әмма Дим кызына карата якты хисләрен дә соңгы көннәренә кадәр саклап кала.

1942 елның 23 гыйнварында, Мәскәүдән Көнбатыш фронтка киткәндә, ул Зәйтүнә Илбаевага хат җибәрә. «Аерылышканнан бирле ничә яз, ничә кыш үтте, – дип яза Җәлил. – Ләкин хыялларымда мин синең белән бик еш очрашам. Кайвакыт радиодан синең җырларыңны тыңлыйм һәм сине Дим ярында күз алдына китерәм. Кунакларда дусларыбыз белән патефоннан «Колый кантон» җырын тыңлыйбыз, синең көмеш тавышың яңгырый. Ә менә күптән түгел, фронт полосасында, бер кызылармияче татар миңа синең портретың белән «Правда» гәзитен күрсәтте. «Сез бу артистны беләсезме, иптәш политрук?» – дип сорады. Фотода мин сине шунда ук танмыдым. Күңелемә шундый рәхәт булды, аңлатып та бирә алмыйм. Кызылармиячнең соравына мин «артистканы беләм» дип җавапладым. Һәм шунда ук башкорт опера театры тарихы һәм аның йолдызы Зәйтүнә Илбаева турында сөйләдем. Аннары озак кына фотога карап утырдым, сине, Дим ярларында очрашуларны искә төшердем. Мин сине сагынам, Зәйтүнә. Менә фронтка килеп җитәбез, сиңа кыр почтасы номерын җибәрермен. Җавап бирерсең бит! Тиздән җиңүгә кадәр. Алладан булып, очрашырбыз. Син дә шуны сора. Хуш. Синең дустың».

Муса Җәлилнең Зәйтүнә Илбаевага язган соңгы хатының эчтәлеге шундый.

Очрашу булмый. Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил туган җиренә әйләнеп кайтмый, фашизмга каршы сугышта һәлак була. Шагыйрьнең үлемсезлеге аның китапларында, Казан Кремле янындагы бронза һәйкәлдә.

Уфаның Дим районында Муса Җәлил урамы (элекке Куйбышев) урнашкан. Урамның атамасын үзгәртү турында карар 1956 елның 13 ноябрендә районның Уфа составына кертелүе һәм шул ук исемдәге урамнар барлыкка килүе белән бәйле рәвештә кабул ителә.

Бүген җәмәгатьчелек шул урамда Муса Җәлилгә бюст кую турында фикерләшә. Изге уйлар тормышка ашсын иде.

Резида ВӘЛИТОВА әзерләде.
«Кызыл таң» газетасыннан.

Сталинградка Татарстан ярдәме

● Сталинградның һәр йорты, һәрбер подъезд өчен сугышлар коточкыч дәрәҗәдә авыр барган.

● Сталинградта немецлар һөҗүме.

Инде өлкән кеше булсам да, илнең сугышсыз яшәгән чорын хәтерләмим. Сугыш туктады, дип шатланырга өлгермисең, һич көтмәгәндә икенчесе башланып китә. Шунысы да бар, һәр сугышта татарстанлылар иң авыр участокларда – алгы сафларда сугыша. Шунлыктандыр, алар беренчеләрдән булып һәлак була. Һәр сугыш бик күп корбаннар китерә. Күпме бала – әтисез, күпме хатыннар ирсез кала.

Шәхсән үзем әтине бөтенләй хәтерләмим. Бөек Ватан сугышы башланганда ул колхоз рәисе булган. Сугыш башлануга аңа бронь биргәннәр. «Тырыш, эшлә. Бөтенесе фронт өчен!» –дигәннәр. Ир-атлар, гарип-горабалардан тыш, барысы да сугышка китеп баргач, күрәсең, авылда калу әтигә оят булгандыр. Хәрби комиссариат ишеген шакый торгач, ниһаять, аны да фронтка җибәрәләр. Дөрес, башта ул Суслонгерда урман кисә, ачлыкка интегә. Берничә айдан соң гына Калуга-Мәскәү юнәлешендәге фашистларны туктатырга тиеш була.

Сугышта әтигә орден-медальләр тапшырылмаган, моның өчен аның вакыты да булмаган. Ул сугышка керүнең беренче көнендә үк һәлак була. Бәлки, беренче сәгатендә, минутындадыр да әле. Безнең гаскәрләргә фашистлар һөҗүмен туктату бурычы йөкләнсә дә, аларның кайберләренә корал да бирелмәгән. Чөнки, ул булмаган. Бернинди коралсыз килеш фашистлар һөҗүмен туктатып буламыни?

Еллар үткәч, миңа да әтиебезнең гомере өзелгән урынны күреп кайту мөмкинлеге туды. Урман эчендәге бер авыл. Элек зур булган, диделәр. Әмма мин килгәндә биредә берничә генә йорт сакланып калган иде. Аларда пенсионер карчыклар яши икән. Атнага берике тапкыр аларга азык-төлек, көнкүреш кирәк-яраклары калдырып китәләр. Почта, аптека, медпункт кебек оешмаларның берсе дә юк. Әтиләр күмелгән зиратны да инде башка авылга күчергәннәр булып чыкты.

Авыл белән танышканнан соң, безнең командирлар позициягә дә бик үк уңышлы сайламаганнар дигән нәтиҗәгә килдем. Сазлыкта урнашкан авыл. Урман сукмагыннан кала юллар юк. Ә немецларның позициясе янәшәдәге тау башында, аннан тирә-як яхшы күренә. Теләгән урыныңны күзәт, тиешле һөҗүмеңне оештыр.

Биредән Казанга кайтканда юл буендагы бик күп каберлекләрне карап уздык. Каберлеккә куелган ташларга бары берничә генә фамилия теркәлгән иде, ә калганнары гомуми саннар исәбенә генә кертелгән. Әйтик, төрле төбәкләрдән килеп һәлак булучылар. Ә башкалары турында «каберлектә фәләнчә йөз, фәләнчә мең сугышчы җирләнде» кебек сүзләр язылган. Фамилияләр арасында татарлар да күзгә чалына. Конкрет фамилияләр нинди принциптан чыгып сайлангандыр, әйтү кыен.

Якташларыбызның һәр сугышта күпләп катнашуы, аларның иң мөһим участокларга җибәрелүе мәгълүм. Бөек Ватан сугышы иң катлаулылардан, озакка сузылганнардан исәпләнә. Ә Сталинград сугышы иң авыр, катлаулы вакыйга буларак тарихка кергән. Ул Ватан сугышында җиңүнең безнең якка борылуына нигез булып торды. Сталинград сугышы 1942 елның 17 июленнән 1943 елның 2 февраленә кадәр дәвам итте. Әлеге сугыш татарстанлылар өчен бигрәк тә истәлекле. Анда республикабызда оештырылган ике укчы дивизия – 120 нче һәм 147 нче дивизияләр катнаша. 147 нчесе Дон буйлап урнашкан Суровикино районы оборонасын 1942 елның июленнән август ахырынача үз кулында тота. Дивизиянең күпчелек солдаты һәм офицеры һәлак була, әмма ул үзенә йөкләнгән бурычны башкарып чыга. Дивизиядәге 4 мең сугышчының дәүләт бүләкләренә тәкъдим ителүе дә гаҗәп түгел. 27 сугышчыга Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

1942 елның 5 сентябрендә Сталинградтан төньяк-көнчыгышта ун чакрым ераклыктагы Ерзовки районында 120 нче укчы дивизия сугышка керә. Аның сугышчылары айдан артык вакыт дәвамында немецларның һөҗүмен туктатып тора. 1943 елның 30 гыйнварында дивизия Идел ярындагы тимер юл вокзалын кулына төшерә һәм 62 нче армия частьләре белән берләшә. Сталинград өчен сугышларда хәрби уңышлары өчен СССР Оборона халык комиссариаты приказы белән 120 нче укчы дивизия 69 нчы укчы гвардия дивизиясе дип үзгәртелә. Пулемет расчеты командиры Р.Галиев, 15 яралы сугышчыны коткарган санинструктор А.Илмәтова һәлак булганнан соң «За отвагу» медальләре белән бүләкләнә. Чүпрәле районының Югары Каракитә авылыннан элемтәче Г.Абделхаков, Тәкәнеш районының элеккеге колхозчысы Г.Гыйззәтуллин, Куйбышев районыннан санинсруктор С. Шителев, Тәмте районыннан лейтенант М.Чикин, Казаннан кече лейтенант П.Евгеньев хәрби бүләкләр ала.

Сталинград сугышында катнашкан 40 тан артык солдатка һәм офицерга Советлар Союзы Герое исеме бирелә. 19 кеше Дан орденының тулы кавалеры була. 44 нче авиация дивизиясе командиры Ф.Фәтхуллин Советлар Союзы Герое исемен сугыш башында ук – 1941 елның 20 ноябрендә ала. 44 нче укчы дивизия архивында Фәтхуллин җитәкчелек иткән 92 нче полкның элеккечә үк дивизия составында иң яхшылардан булуы әйтелгән документ саклана.

Арча районының Иске Кишет авылында туган полковник Гани Сафиуллин Сталинград фронтында 38 нче укчы дивизиягә җитәкчелек итә. Сталинград дивизиясе аның җитәкчелегендә дошманның 18 мең сугышчысын әсирлеккә ала, 68 танкын, 22 самолетын кулга төшерә, 100 дән артык танкы һәм автомашинасы юк ителә. 1943 елның 26 октябрендә Днепрны уңышлы кичүе өчен Г.Сафиуллинга Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

Сталинград урынында җимерекләр генә утырып кала. Сталинград янында фашистлар төркемен юк итүгә Татарстан АССР исемендәге, Кызыл байрак орденлы 202 нче урта Дон авиация дивизиясе зур өлеш кертә. Ул республика халкы акчасына җыелган Пе-2 бомбардировщиклары белән коралланган була. Дивизия Сталинградтан Берлинга кадәр юл үтә. Соңгы очышларын ул Германия җиңелгәч, Прага янында ясый.

Якташларыбыз гаскәрләрнең барлык төрләрендә сугыша. Сталинград өлкәсендәге сугышларда ТАССРдан 22 меңнән артык солдат һәм офицер һәлак була. Аларның 811 е урам сугышларында ятып кала.

Татарстаннан Сталинград оборонасы өчен кирәкле җиһазлар да җибәрелә. Аларны бригадалар урынга барып хәрби шартларда ремонтлый. СССР Суднолар төзү халык комиссариатының 340 нчы заводы хәрби суднолар төзү белән шөгыльләнә. Сугыш чорында ул 7 зур судно, 77 диңгез бронекатеры, 7 буксир, 5 тралбарс эшләп чыгара. Казанлылар заводта хәрби суднолар да ремонтлый. Суднолар төзү комиссариаты приказы белән заводка 1943 елның 7 июнендә рәхмәт белдерелә.

Хәрби суднолар белән беррәттән завод снарядлар, зенит җайланмалары, аэрочаналар өчен җиһазлар ясый. Сугыш чорында завод снарядлар җитештерүне аена 23 тапкыр арттыра. Бу хакта 2004 елда чыккан документлар һәм материаллар тупланмасында теркәлгән.

Татарстан тимерьюлчылары Юдино станциясендә үз акчаларына «Кызыл Татарстан», «Чапаев», «Куйбышев» кебек куәтле бронепоездларны җыя. Аларның экипажлары Сталинград өчен сугышларда да катнашкан була.

Сталинград фронтының 63 нче армиясенә 47136 сумлык җылы киемнәр озатыла. Авиация частьләренең берсенә 3030 сум торган язу машинасы җибәрелә, ә «Сталинградское знамя» фронт газетасына язу машинкасы, шрифтлар, копирация кәгазе бирелә. Редакциягә татар телендә эшли белүче хәреф җыючылар, машинистлар, текст басучылар да табып озатыла.

1943 елның 17 мартында «Красная Татария» газетасында Ф.Ковальский мәкаләсе урнаштырыла. Анда Сталинградны торгызу өчен төрле яклап ярдәм кирәклеге күрсәтелә. ТАССР Халык комиссарлары советының 1943 елның 21 маенда кабул ителгән 219 нчы карары нигезендә Сталинградка трактор заводын торгызу өчен төзү материаллары: известь, кирпеч, алебастр җибәрелә. Аларны Казанның «Строитель» кирпеч комбинаты, Казан известь-алебастр заводы, 7 һәм 8 нче заводлар, «Металлопромсоюз» системасы предприятиеләре, «Труд-кирпич», «Волгопром», «Победа» промкооперация артельләре житештерә.

Сталинградлылар Татарстан халкына рәхмәтле булып калды. Алар бүген дә музей, архив экспонатларында саклана, галимнәр аларны җентекләп өйрәнә.

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ.

Галия ГАЙНЕТДИНОВА

Акны ак дип өйрәнгәнгә микән, Караны ак дия алмадым...

ТУКАЙ РУХЫ РӘНҖЕМӘСЕН

Тукай иҗатыннан илһам алган
Шигырь язмый яши аламы?
Үзен шагыйрь иткән остазына
Бер багышлау язмый каламы?

Языйм әле, хакым бар, дип уйлыйм
Бер багышлау кыска булса да.
Бүгенгене тартып бара, диеп,
Йөз кырыгы тиздән тулса да.

Күпме җаннар киткән бу дөньядан
Аркылыны буйга салмыйча?
Мирас итеп изге туган телен
Баласына бирә алмыйча.

Бүген дә күп андый битарафлар
Илен, телен яклый белмәгән.
Әрәм үтә гомер, беркем дә бит
Ике яшәр өчен килмәгән.

Күпме икән телебезнең гомере?
Күпме икән милләт гомере?
Җуйсак телне, кунмасмы йөзебезгә
Бу дөньяның кара сөреме?

Әйтер сүзебезне йотып эчкә,
Милләттәшләр, тормыйк, калтырап.
Рәнҗемәсен Бөек Тукай рухы
Бүгенгене күреп, аптырап.

ГАРМУН УЙНЫЙ БЕРӘҮ

Хискә чумып, гармун уйный берәү,
Җитез бармаклары төймәдә.
Бер кушылып җырлыйсылар килә
Ул уйнаган таныш көйләргә.

Гармун уйный, тынмый,
Кемдер туктап тыңлый.
Эшләпәгә төшә ун тәңкә.
Кемдер хәтта ишетмичә үтә,
Аның хәле яхшы бик күпкә.

Битарафлар белән дөнья тулган,
Гармуннарны заман оныткан.
Кемдер әйтер эчтән, кулын селтәп:
– Гармун уйнап кем соң баеккан?

Гармун уйнап беркем баекмаган,
Теләге дә андый булмаган.
Уйнаган ул, чөнки халкы аның
Гармун моңнарыннан туймаган.

Кемдер яши кәеф-сафа корып,
Тел ни аңа, иҗат, сәнгать – ни.
Алпан-тилпән кайтып ава көн дә,
Көн башламый башын төзәтми.

Ул – кызганыч, ә гармунчы түгел,
Көне үтсә дә уйнап урамда.
Шәп уйный бит, тик уйнасын гына,
Күңелле ул уйнап торганда.

Тыңлап торам туктап,
Һич җәл түгел вакыт.
Эшләпәгә төшә йөз тәңкә.
Афәрин! дип меңне бирер идем
Гармунчыга мин шушы мәлдә.

КАРАНЫ АК ДИЯ АЛМАДЫМ

Җигелсәм дә төпкә, күрмәделәр,
Тырышсам да мактый белмәделәр.
Хак булса да, әйткән сүзләремне
Никтер колакка да элмәделәр.

Аз эшләп тә кемдер күп каерды,
Башлыкларга ярый белгәнгәдер.
Гайбәт сатып, кеше хезмәтеннән
Файдаланып гомер сөргәнгәдер.

Яшибез шул гаделлек һәм намус
Җитенкерәмәгән заманнарда.
Шулар җитми безнең яшәешнең
Тишек урыннарын ямауларга.

«Яхшы» диеп хисап бирү кирәк,
Шуны сорый бүген заманасы.
Өстәп куярга да өйрәнгән без,
Чыга калса эшнең яманаты.

Акны ак дип өйрәнгәнгә микән,
Караны ак дия алмадым.
Безнең урамда да кояш чыгар,
Диеп күңелне һаман алдадым.

АГЫМНАРГА КЕРӘМ

Алга барып булмый,
Язмыш киртә корса.
Барыр юлың бүлеп
«Айсберг»лар торса.

Адым саен «айсберг»
Бәгырьгә таш элә.
Гел каршыга чыга,
Юлны бүлә-бүлә.

Җилгә каршы бару
Җиңел түгел, беләм.
Каршы йөзәр өчен
Агымнарга керәм.

Агымнарга керәм
Инде ничәнче кат.
Андый чакта була
Дус-ишләрең дә ят.

«Айсберг»лар алар –
Бездән өстәгеләр.
Дөнья алар өчен
Алсу төстә генә.

Ялагае йөзә
Әнә, балда, майда.
Кара көнчеләре
Гайбәт сата янда.

Нишләр алар ахыр
Тәкъдир кызганмаса.
Күргән дөньялары
Алсулыгын җуйса?

Сөзеп яшәгәннән
Чыкмый башка «мөгез».
Соңгы юлга җиткәч,
Бөтен кеше тигез.

ҮТӘЛЕРГӘ ТИЕШ ӘМАНӘТ

Әби-баба элек-электән үк
Телгә битарафлык кылмаган.
Туган телнең моңын, кадерен ул
Сабый чагыннан ук аңлаган.

Ана телебез яшәргә
Тиеш саф, бөтен килеш.
Үзебез сакламый аны
Кем соң сакларга тиеш?

Кыскартырга тырышалар
Мөмкинлекләрен күптән.
Телебезнең ирке, имеш,
«Тиеш»тән узып киткән.

Яклар өчен телебезне
Кузгалыйк, агай-эне.
Чүпләнеп һәм гарипләнеп
Бара бит татар теле.

Кадерсезләнгәнгә күрә
Тел өстенә мүк үсә.
Яшьләнер иде Тукайның
Күзләре, моны күрсә.

Бәлки, һуштан язар иде,
Гаделсезлекне күреп.
Чөнки татар үзе яши
Туган телгә төкереп.

Сәяхәттә, диңгез, далаларда,
Чүлдә татар телен җуймаган,
Һәм кемнәндер таптатырга аны,
Кимсетергә ирек куймаган.

Теле барның үз милләте булган,
Милләтленең иле, дәүләте.
Телен яклаганның даны арткан,
Саклаганның арткан кодрәте.

Ирексезләп, сине биздерергә
Теләсәләр туган телеңнән,
Теләсәләр читтә яхшырак дип
Биздерергә туган илеңнән,

Кендек каның тамган изге җиргә,
Ана сөте белән иңгән телгә
Беркайчан да итмә хыянәт.
Сакла телең, татар баласы, бу –
Үтәлергә тиеш әманәт.

ЯКЛЫЙК ТУКАЙ ХАКЫНА

Кыйналды тел, кимсетелде
Ябылды зинданнарга.
Куймыйк ирек аны кабат
Хаксызга яраларга.

Киләчәк кичермәс безне
Телгә зыян китерсәк.
Яңа буын сабыйларын
Туган телсез үстерсәк.

Югалмас, газиз телебез
Сеңеп калса алтыда.
Телебезне тел тидерми
Яклыйк Тукай хакына!
Яклыйк милләт хакына!

КЫЛДЫҢМЫ СИН ҖИРДӘ ИЗГЕЛЕК?

Ходай сиңа яшәр гомер биргән,
Биргән суын, биргән җимешен.
Үсеп җитешеңә көткән сине
Өлешеңә тияр көмешең.

Сине көткән кырлар, озын юллар,
Чикләвекле таулар көткәннәр.
Чишмә чыккан бәреп җир астыннан,
Бакчаларда гөлләр үскәннәр.

Сукмакларда бәбкә үлән үскән,
Ап-ак чәчәк аткан алмагач.
Иркәләнеп син йоклаган чакта,
Җырын бүләк иткән сандугач.

Җил-давылдан, салкын бураннардан
Әткәң-әнкәң сине саклаган.
Ялгыш гамәлләрең гел кичереп,
Бөтенесе сине яклаган.

Һәр әзергә бәзер булып шулай
Үстердең син акыл, буеңны.
Җиңел ашырдың син тормышка да
Һәр хыялың, һәрбер уеңны.

Гамьсезлектә сине гаепләмим,
Яшьлегеңдә күпләр ваемсыз.
Әйтер сүзем: кылма дуамаллык,
Булма харап, булма син сансыз!

Уйлап кара, үзең шушы җирдә
Кылдың микән берәр изгелек.
Кем өчендер ихлас күңел белән
Күрсәттеңме берәр игелек?

КАЗАННЫҢ ИКЕ ҺӘЛАКӘТЕ

ЯКИ ни өчен Явыз Иван Казанны 7 ел дәвамында, ә Пугачев – 3 сәгатьтә яулаган?

● Явыз Иван (сәнгатьтәге образ).

● Емельян Пугачев (сәнгатьтәге образ).

Һөҗүмнәре 1545 елда башланып, кабатлана-кабатлана 7 елга сузылса да, Явыз Иван 1552 елда Казанны барыбер 1 ай да 11 көн буе камап торырга һәм дистәләгән көндәлек бәрелешләр алып барырга мәҗбүр була. Ә Пугачев исә үзе: «Патша Иван Васильевич Казанга 7 ел буе теш кайраган, ә мин бу каланы 3 сәгать эчендә көлгә күмдем», - дип язып калдырган. «Көл астында калдыру» әле шәһәрне тулысынча яулау дигән сүз түгел бит, ә икенче яктан караганда, 1545 елдан башлап барлык уңышсыз омтылышларын кертеп санаганда, Иван патшаның Казанны яулавы чыннан да 7 елга сузылган, дип әйтеп була. Бу мәсьәләгә ачыклык кертү сорала.

● Ике антипод - Емельян Пугачев һәм Иван Михельсон.

1552 елгы фаҗига

Явыз Иван (төгәлрәге, аның тәҗрибәле воеводалары, чөнки ул үзе камау белән җитәкчелек итмәгән, поход чиркәвендә гыйбадәт кылып кына утырган) җитди каршылыкка очраган – татарлар бирелергә җыенмаган һәм үз ватаннары өчен бер кызганусыз җаннарын да бирергә әзер булган. Ул чакта Казан бәйсез дәүләт башкаласы булган бит, аның горур халкы үз азатлыгы өчен соңгы тамчы канынача көрәшергә атлыгып торган. Диварларны шартлатып шәһәргә кергәннән соң, мәскәүләргә һәр йорт һәм һәр урам өчен күп кан түгәргә туры килгән. Шул вакыйгаларның шаһиты булган Андрей Курбский язуынча, кыю яугирләр батыр Казан халкы белән сугышкан арада ныгытма эченә кермәгән рус гаскәриләре *«ринулись в крепость, так что лежавшие под именем раненых вскочили, а притворявшиеся мертвыми воскресли. И не только они со всех сторон, но и кашевары из станов, и те, кто был у коней оставлен, и те, кто с товарами приехал, – все сбежались в крепость не для бранного подвига, а за обильной добычей. И действительно, город был полон самой дорогой добычи – золота, серебра, драгоценных камней, кипел соболями и иным великим богатством».*

Башкала эчендә сугыш дүрт көн барган. Шәһәр халкының күпчелеге хан сараена кереп котылмакчы булган – бирегә бөтен яктан картлар, хатын-кызлар һәм балалар агылган. Никон елъязмасында бу турыда:*«Воины же православные приближались к цареву двору и секли нещадно нечестивых, мужей и жен, так что по низинам текла их кровь»*, дип язылган. Дүртенче көн азагында Казанны яклап көрәшерлек бөтен сугышчы кырылып беткән, Ядегәр-Мөхәммәд хан әсирлеккә төшкән, ханлык та, аның халкы да җиңүче патша кулына күчкән.

Шул ук Никон елъязмасында язылганча, Казан алынганнан соң исән калган бөтен ир-ат үтерелгән, хатын-кызлар һәм балалар кол ителгән: *«В полон же повелел царь имати жены и дети малые ... и столь множество взяли полона татарского, что все полки русские наполнились: у всякого человека русского полон татарский был; христианского же полону множество тысяч душ освободили».*

1774 елгы камалыш

1774 елның июнендә Пугачев Мәскәүгә юнәлә. «Падишаһ Петр Федорович галиҗәнапләренең» юлы Казан аша үтә. Ул чакта шәһәрдәге гарнизонда нибары өч батальон, анда барлыгы 1500 кеше исәпләнә, Пугач патша белән исә 15 меңләп фетнәче килә. Бөтен Казанда атарга яраклы нибары 143 мылтык һәм 200 пар пистоль табыла. Гимназия үз акчасына 450 карабин һәм сөңге сатып ала.

Казан тирәли саклагыч корылмалар бөтенләй булмый диярлек. Карт генерал-аншеф фон-Брандтан һәм армиядән булдыксызлыгы өчен куылган генерал-поручик Петр Баннердан гыйбарәт шәһәр хакимияте периметрның бер өлешенә редут һәм редантлар төзетә, әмма аларның күпчелеге салынып бетмәгән була. Төп батареяны саклану

● «Пугачевның Казанга һөҗүме». Ф. А. Моллер картинасы.



● «Казанны яулау күренеше». Н.Дмитриев-Оренбургский рәсеме.

сызыгының көнчыгышына куялар. Даими гаскәрдән тыш, гади гражданнар да коралландырыла. 74 гимназисттан корпус төзиләр, шулардан 39 ы карабин һәм сөңге белән коралланган була.

Казан тарихчысы С.Саначин:*«Оса, Воткинск, Ижевск яулап алганнан соң Казанда хәвефләнү көчәя. Халык шәһәрне ташлап кача башлый. Губернатор һ.б. югары түрәләрнең гаиләләре Казаннан чыгып китә... Мәскәүгә йөк төялгән иксез-чиксез арбалар агыла»*, – дип язган.

Пугачев гаскәренә исә юлында яңа штыклар өстәлә тора. Казанга җиткәндә, аларның саны 20 меңнән арта. Казанга Петербургтан генерал-майор П.Потемкин килә. Ул фетнәчеләргә каршы отставкадагы полковник Н.Толстой җитәкчелегендә отряд җибәрә. Йөз җәяүле, йөз карабинчы һәм бер тубы булган отрядны Пугачев җибәргән мең кеше кырып сала, Толстой чәнчеп үтерелә. Шуннан соң Казанда паника башлана. Кем Мәскәүгә, кем Сембергә, кем Пензага яки башка шәһәрләргә кача башлый.

Пугачев һөҗүме

Явыз Иван кебек үк, Пугачев та башта казанлыларга яусыз бирелергә тәкъдим итә, әмма алар баш тарта. Пугачевка исә сатлыкҗаннар сиздермичә генә шәһәргә керү юлларын күрсәтә. 12 июль иртәсендә һөҗүм һәм штурмлау башлана. Пугачев 20 сажин ераклыктан Спас монастырена туплардан ата. Әмма һөҗүм уңышсыз тәмамлана, 100 кешесен югалтып, ул чигенә. Аның фәрманы буенча башкортлар шәһәргә ут төртә. Коточкыч көчле янгын башлана. Кирмән эченә меңнән артык кеше кереп тула, паника башлангач, Потемкин икесен астыра, паника шуннан соң гына тынгандай була.

Генерал И.Михельсон хәрби-поход журналында болай язып калдырган: *«Казанны талау таңнан алып төнгә кадәр дәвам итә. 25 чиркәү, 3 монастырь, 1772 торак йорт (нибары 298 йорт кына янмый кала), Постау бистәсендә 186 йорт (492се янмый), Ямчылар бистәсендә 105 йорт (20се генә янмый) янып бетә, баш күтәрүчеләр йөзләрчә кибет урнашкан Сәүдә йортын талый; төрмәдән 153 җинаятьче азат ителә; 162 казанлы үтерелә, 129 ы яралана, 486 сы хәбәрсез югала»*.

Төнлә Арча кырында Пугачев 1 мең әсирне туплар каршында тезләндерә һәм үзенең сугышчыларына ял бирә. 12 мичкә шәраб китертелә, мәҗлес гөрли. Ә бу вакытта Казанга талантлы полковник Иван Михельсон отряды якынлаша. Ул мәҗлеснең иң кызган чагына килеп җитә һәм үзенең 800 солдаты белән лагерьга бәреп кереп, исерек фетнәчеләрне кыра башлый. 5 сәгатьлек төнге сугышта Пугачев җиңелә һәм кача. Михельсон кырда куна һәм иртән Казанга юнәлә. 15 июльгә Пугачев 25 меңлек гаскәр туплый һәм Михельсоннан үчен кайтарырга җыена. Беренче яу урынында кабат очрашалар. 4 сәгатьтән соң ялган патша галиҗәнапләре тулысынча тар-мар ителә, бөтен армиясен һәм артиллериясен югалта. 10 меңнән артык Казан кешесе азат ителә.

Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА
тәрҗемәсе.

● «Пугачев Казанда суд үткәрә», 1931 елгы почта карточкасы. СССР Революция музее басмасы.

Чыңгыз АЙТМАТОВ

ДӨЯ КҮЗЕ

(Дәвамы. Башы 35, 36, 37, 38, 39 нчы саннарда).

«Мөмкинлек килеп чыгу белән аны эзләп табып, бөтенесе турында ихлас күңелдән сөйләшергә кирәк» дип, үз-үземә сүз бирдем. Шул очрашу турында хыяллана башладым, мин аның белән очрашырга телим һәм шуңа ышана идем.

Нәкъ әнә шул көннәрдә без кырда яңгырга эләктек. Яңгыр болыты бик тиз килеп җитеп, көтмәгәндә генә яварга да тотынды. Боз катыш коеп ява торган көчле дала яңгыры иде бу. Һава шаулап-гүләп тора башлады, күз ачып йомганчы җир өсте кайнап, күбекләнеп торган күлләвекләр белән капланды. Ләкин Әбәкер тракторны туктатмады. Киресенчә, ул аны кызурак чаптыра башлады, бозлы яңгыр астында утырсам да, миңа бер тапкыр да әйләнеп карамады.

Су сеңеп күбенгән туфрак катламнары хәзер инде төрәннән кайтарылып әйләнеп төшми. Алар сабанны каера, рам өстенә, минем аякларга менә иде. Трактор чылбырына әйләнмәслек булып балчык сыланмаса, ихтимал, Әбәкер гомумән туктамас иде әле. Шул хәлдән соң гына ул моторны сүндерде дә кабинасында җәелеп утырып тәмәке тартырга кереште, үзе янына, ышыкка мине дә килеп җитәр дип уйлады, ахры. Ләкин хәзер инде минем өчен барыбер. Мин җеп бөртегемә хәтле чыланган идем. Шуңа күрә сабаннан төшмәдем, өстемдәге тузан-пычракны яңгыр суында юдырып утыра бирдем. Яңгырдан сакларга тырышкан бердәнбер нәрсәм блокнот иде. Анда кайбер кирәкле нәрсәләр һәм укыган китапларымнан кызыклы фикерләр язып куелган иде. Блокнотны итек кунычына тыктым.

Яңгыр кул белән алып ташлагандай капыл гына басылып та китте. Күк йөзе шундук ачылып, төпсез саф зәңгәрлеге белән балкып тора башлады. Ул гүяки язгы юмарт ләйсән яңгыры белән юылып калган иркен дала матурлыгының һәм сафлыгының дәвамы иде. Очсыз-кырыйсыз Анархай киңлекләре тагы да киңәя, тагы да иркенәя башлаган сыман булды. Бөтен күк гөмбәзен иңләп, Анархай өстенә салават күпере сызылды. Ул дөньяның бер читеннән икенче читенә дугаланып төште дә, җир йөзендәге иң нәфис төсләрнең барчасын үзенә туплап, күк йөзендә катып калды. Мин таң калып тирә-ягыма карандым. Өрфиядәй җиңел, зәп-зәңгәр күк йөзе, җем-җем итеп торган аллы-гөлле салават күпере һәм төсе сулган әремле дала! Җир өсте бик тиз кипшереп килә, ә һавада, бик биектә, канатларын киереп җәйгән килеш бер дә какмыйча-селкетмичә, бөркет әйләнеп оча. Әйтерсең шундый биеккә ул үзе менмәгән, канатлары менгезмәгән аны, бәлки җирнең куәтле сулышы, өскә бөркелгән җылы һавасы белән бөркет югарыга ашкан иде.

Һәм шунда яңадан үземдә көч уянганын тойдым, минем дә рухым канат җәйде, Анархай турындагы хыялларым күңелемдә яңадан терелде. Әйе, хәзер инде мин җир өстендә нык басып торам, беркем минем хыялларымны җимерә, Анархай даласының матур киләчәгенә ышанырга комачаулык итә алмый иде. Мин шагыйрь булмасам да, мәктәптәге стена газетасында ара-тирә шигырьләрем чыккалый иде. Менә хәзер дә итек кунычыннан блокнотымны чыгардым да шул минутта ук күңелемә килгән беренче сүзләрне кәгазьгә төшердем:

Курдай калкуының аръягында
Тып-тын яткан аулак дала бар, –
Эссе җилләр аны киптергәннәр,
Котырынган карлы бураннар.
Мин беләмен аның киләчәген,
Ул көн якын, ул көн туачак,
Ак әремле Анархай даласы
Гөл-бакчалы бер ил булачак.

Мин бу шигырь юлларының килешсез-ипсез чыгуына борчылмадым, киресенчә, күңелемдә айкалган хисләремнең йөздән бер өлешен дә әйтеп бирә алмавыма кәефем китте. Хыялымда тойганнарымны нинди сүзләр белән чәчми-түкми әйтеп бирим икән дип баш ватып утырганда, кинәт кемдер, килеп, кулымнан блокнотымны тартып алды. Мин борылып карадым.

– Мәхәббәт шигырьләре чыгарасыңмы! – диде Әбәкер, мыскыллы көлеп, һәм бер читкәрәк китте. – Шигырь белән караткмачы буласыңмы кызны?..

– Бир блокнотымны! – дип ярсып, аның янына йөгереп килдем. – Кеше әйберсен уку яхшы түгел!

– Яхшымы-яманмы, анысын син миңа өйрәтмә! Анысын мин үзем беләм! Кит янымнан!

Мин:

– Әле алаймыни! – дидем дә, трактор янына йөгереп барып, кулыма отвертка алдым.

– Сугып кара! – диде Әбәкер, йодрыгы белән янап. – Мә тузга язмаган нәрсәңне, – дип, ул миңа блокнотны кире кайтарды, аннары беравыктан бөтен даланы яңгыратып кешнәп көләргә тотынды. – Анархай иле, имеш! Ха-ха-ха! Җүләр дә соң син, Академик! Монда нәкъ менә синең ишеләрне генә китерергә кирәк тә, дөньяның нәрсә икәнен белеп китәр идегез!.. Анархай иле, имеш! Ха-ха-ха! Үзенең нинди ил икәнен күрсәтер әле ул сиңа! Монда кыш чыгарга гына кал, бөтенләй башкача сайрый башларсың...

– Кыш чыгарга каламмы-юкмы, анысын синнән сорамам! Иң элек үзең турында уйла!

– Нәрсә уйлыйм мин? — Әбәкер, караңгы чырай белән мыскыллы гына көлеп, минем өскә килә башлады. – Минем үз уем үзем белән. Кая барсам да, үземнекен алмый калмам. – Ул минем яннан китә башлаган иде дә нәрсәдер исенә төшеп туктады, аннары миңа якын ук килде дә тавышын кыса төшеп әйтте: – Ә син, Академик, ул кыз турындагы уйларыңны башыңнан чыгарып ташла, өметләнмә.. Җаныңны алырмын!

– Анысын карарбыз әле!

– Ә мин сиңа әйтәм, андый уйны башыңа да китермә!

Аныңча эшләмәгән бөтен кешегә карата ачу-нәфрәт саклап йөргән, шуның белән акылы түнгән бу йөгәнсез кешене хәтта кызганып та куйдым. Шуннан соң тыныч кына әйттем:

– Олы кеше син үзең. Вакыт-вакыт дөрес сүзләр сөйлисең. Тик монысы очраклы гынадыр, сукырлыктандыр. Бернәрсәне исеңдә тот: беркем бер кешене дә уйлаудан, теләгенә омтылудан, хыяллавудан тыя алмый. Кешеләр уйлый белүләре белән хайваннан аерылалар да.

Бу сүзләремнең аңа тәэсире булгандырмы-юкмы, анысын белмим, ләкин ул ләм-мим эндәшмәде. Караңгы бер чырай белән трактор янына юнәлде дә каты итеп пускачны әйләндереп җибәрде. Двигатель җиңел генә кабынып китте, безгә яңадан эшкә тотынырга кирәк иде...

Шул сәгатьтән соң инде үземнең хыялларымнан бүтән аерылмадым. Мин аларны яулап алдым, мин хыялланырга яңадан хокук алдым. Ул хыяллар, күңелемнән чыкмыйча, үзем белән бергә яши башладылар.

Кич, бөтен кеше йокларга ята башлагач, мин, тирмәдән чыгып, чишмә янына киттем. Ни сәбәптәндер шунда барасым, ялгыз каласым килә иде.

Күк йөзе чүп-чуар йолдызлар белән тулган, алар офык буена, җиргә хәтле сибелешеп төшкәннәр. Тик шунысы гаҗәп: күбесе, дөресрәге, баш турысында җемелдәшеп торганнары барысы да, нинди хикмәт беләндер, чишмә йөзенә дә сыешып беткәннәр, шушы минутта төпсез тирән булып тоелган кечерәк кенә түгәрәк бер су өстендә чагылалар. Чишмә суында алар нурланып, җем-җем итеп торалар – теләсәң чумырып ал да утлы тәңкәләр төсле җиргә чәчеп җибәр. Инеш агып яткан төштә алар, ташлы төптә чарпаланып ватыла-ватыла, су белән бергә агып китәләр. Ә су өсте уйчан гына булып тынып калган төштә исә алар күк йөзендәге шикелле үк җем-җем итеп нурланып торалар иде, шуңа күрә мин, кайвакыт дала чишмәсе нәрсәсе беләндер кеше күңеленең хыял белән тулган якты чагын, үз эченә бөтен дөньяны сыйдырырдай тирән чагын хәтерләтә дип уйлап куйдым.

Чишмә янында мин тирә-ягымдагы дөньяны карап, тыңлап утырдым, тынып калган төнгә даланы бөтен җаным-тәнем белән тоеп, күңелемә сеңдердем, аны үземчә хыялларыма төреп яңарттым. Шуларны кемгә сөйлим, кем белән уртаклашыйм икән? Маңгаенда бер тотам чәч чугы йөрткән, үзем әле исемен дә белмәгән теге кыз миңа нәкъ әнә шундый кешедер кебек тоелды. Аның ни өчен шундый булып тоелуын аңлата алмыйм. Ул мине, билгеле, аңлар иде, күңелемә тулышкан хисләремне уртаклаша белер иде. Бәлки, беренче тапкыр мин аның белән шушы чишмә янында очрашканга, шушы чишмәгә «Дөя күзе» дигән исем кушканга шулай тоелгандыр.

Кайда икән ул кыз хәзер, минем үзе турында уйлавып утырганымны белә микән? Озакламый без сөрәсе җирне сөреп бетерербез, шуннан шуннан соң аны табып, шушында чишмә янына алып килермен дә Анархай иле турында сөйләрмен. Шигырь белән түгел, юк, – йә көләр үземнән! – гади сүзләр белән, гади генә итеп Анархай даласында булачак тормышны сөйләп бирермен.

Кайтырга җыенгач, йолдызлар сибелешкән күк йөзенә тагын бер тапкыр күз йөртеп чыктым. Күргән кадәресен карап туя алмый иде күзләрем. Калкулык битендә, һәрвакыттагыча, тонык бер карамчык төсле булып, килбәтсез таш сын басып тора. Мин аның менә хәзер дә бөтен дөньяга гамьсез бер кыяфәттә, җансыз, мәгънәсез карашлы сыңар күзен каядыр еракка төбәп басып торуын күз алдыма китердем.

Ул арада ай калыкты һәм шул яктыда сөрелгән кишәрлекнең теге ягында сакланып кына хәрәкәт иткән ике шәүлә күренде. Болар җәйрәннәр – дала кәҗәләре иде. Кая бара икән алар? Су эчәргәдер. Җәйрәннәр басуның читенә үк килеп җиттеләр дә шып туктап калдылар, бик сәер булып йомшартылган, нефть һәм тимер исе аңкып торган җиргә аяк басарга батырчылык итмәделәр. Алар, ай яктысы астында беркадәр көмеш төсенә кереп, бер дә селкенмичә-кымшанмыйча, шактый озак басып тордылар. Тәкәсенең җәпле-җәпле мөгезләре бар, анасы тәбәнәгрәк, зур күзләре караңгыда ялтырап тора иде. Анасы тәкәгә сыена төште, анысы шикелле үк, җиңел башын ялт кына күтәреп, сагаеп калды. Алар әнә шулай тып-тын булып каткан хәлдә басып тордылар. Аларның бөтен килеш-килбәте курку-сагаю һәм «Далага ни булды болай? Иске сукмак кая китте? Нинди көч җирне шулай актарып ташлады?» дип сорау галәмәтен белгертеп тора иде.

Җәйрәннәр барыбер басу аша узарга батырчылык итмәделәр. Кире борылдылар да тып-тын гына китеп бардылар, сыгылмалы зифа билләрендә көмештәй ай нурының моңсу шәүләсен алып киттеләр.

Җәйрәннәр тыныч кына китеп барсыннар дип, мин тагын бераз утырып тордым. Аннары тирмәгә кайтып, караңгыда үз урынымны эзләп таптым, байтак вакыт йоклый алмыйча яттым.

Шунда пышылдашып сөйләшкән тавыш ишеттем. Әбәкер белән Хәлифә бергә ятканнар иде. Ихтимал, моңарчы да шулай булгандыр, тик мин моны белмәгәнмен генә. Хәлифә сулкылдый-сулкылдый нәрсәләрдер әйтә иде, аның нәрсә әйткәнен ачык ишетә алмадым.

– Йә, җитәр инде, булды, — дип, йокылы тавышы белән мыгырданды Әбәкер. – Менә калага кайтырбыз, шунда барысын да җайларбыз. Бер-ике көн ятып чыгарсың... Нигә бер дә юкка шулхәтле хафаланасың?

Хәлифә ачынып җавап кайтарды:

– Анысы өчен хафаланмыйм мин. Үземне үзем куралмыйм... Ни дип яраткандыр мин синең ише кешене? Нәрсәгә исем киткәндер, аңламыйм... Кешеләргә берәр яхшылык эшләгәнең бармы синең? Юк бит, эт шикелле үзем тагылдым...

– Үкенмәссең. Менә эшне бетерик тә алып китәрмен.

(Дәвамы киләсе санда.)

(Ахыры. Башы 38, 39 нчы саннарда).

Сафиуллин Нуртдин Сафиулла улы шул ук Туймазы хәрби комиссариаты тарафыннан 1918 елның май аенда ук Кызыл армиягә мобилизацияләнә. 1899 елда туган, 1927 елга ВКП(б) сафына кергән бу каһарман Бөек Ватан сугышы барышында Брянск, Воронеж, Үзәк һәм 3 Украина фронтларында яу йөри. Яу кырында татар улы Кызыл байрак, 3 дәрәҗә Суворов, 2 дәрәҗә Ватан сугышы орденнары белән бүләкләнергә өлгерә, гвардия полковнигы, 2 нче механикалаштырылган гвардия корпусының 6 нчы бригада командиры дәрәҗәсенә җитә.

1944 елның 22-23 декабрьларында Сафиуллин бригадасы Венгриянең Валь, Етьек пунктларын яулый, 24 ендә илнең башкаласы Будапештка бәреп керә. 4 гыйнварда бригада дошманның танк һәм авиация кулланган 6 контрһөҗүмен кире кага. 5 гыйнварда гитлерчылар Шаришап бистәсе янында совет оборонасының чылбырын өзүгә ирешәләр. Яңа һөҗүмнәр оештырып йөргән бер мәлдә Сафиуллинның башы каты яралана. Ләкин бригада үз позициясеннән чигенми. Каһарманлыгы өчен 1945 елның гыйнварында Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителсә дә, госпитальдә полковник үзенең 2 дәрәҗә Кутузов ордены белән генә бүләкләнүен белеп ала.


полковник САФИУЛИН был тяжело ранен в голову.
Героические действия 6-й гвардейской мехбригады, удерживающей ТД противника в районе ШАРИШАП, дали возможность произвести соответствующую перегруппировку соединений и обеспечить устойчивость корпуса.
За отличное выполнение боевых операций, умелое и стойкое руководство в проведенных боях, личный героизм и отвагу, гвардии полковник САФИУЛИН достоин присвоения звания ГЕРОЯ СОВЕТСКОГО СОЮЗА.
КОМАНДИР 2 ГВАРДЕЙСКОГО МЕХАНИЗИРОВАННОГО НИКОЛАЕВСКОГО КОРПУСА
ГВАРДИИ ГЕНЕРАЛ-ЛЕЙТЕНАНТ
/СВИРИДОВ/
III. Заключение Военного Совета Армии
"9" января 1945 г.
...награждения орденом "КРАСНОГО ЗНАМЕНИ".
КОМАНДУЮЩИЙ БРОНЕТАНКОВЫМИ И МЕХАНИЗИРОВАННЫМИ ВОЙСКАМИ 46 АРМИИ
ПОЛКОВНИК /РУМЯНЦЕВ/
10 ... 1945 г.
Командующий Армией ______ (звание)
Член Военного Совета ______ (звание)
Начальник штаба ______ (звание)
"__" ______ 194__ г.
IV. Заключение Военного Совета фронта (округа)
Достоин ордена Ленина
Командующий Войсками 46 Армии
Генерал-лейтенант
/ФИЛИПОВСКИЙ/
Член Военного Совета Армии (звание)
Генерал-майор
/КОНОВАЛОВ/
2 февраля 1945 г.
V. Заключение наградной комиссии НКО
ДОСТОИН награждения орденом КУТУЗОВА 2 СТЕПЕНИ
П.П. КОМАНДУЮЩИЙ ВОЙСКАМИ 3 УКРАИНСКОГО ФРОНТА МАРШАЛ СОВЕТСКОГО СОЮЗА /Ф. ТОЛБУХИН/.
П.П. ЧЛЕН ВОЕННОГО СОВЕТА 3 УКРАИНСКОГО ФРОНТА ГЕНЕРАЛ-ПОЛКОВНИК /ЖЕЛТОВ/.
Председатель
Члены 1. 2.
Верно: НАЧАЛЬНИК ОТДЕЛА КАДРОВ 3 УКРАИНСКОГО ФРОНТА ПОЛКОВНИК /БОЧАРОВ/.
"__" ______ 194__ г.
VI. Отметка о награждении

Йолдызсыз калган татарлар

* * *

Хәтта, әлеге каһарманнарның гаилә әгъзалары, уллары-оныклары да үз бабаларының Бөек Ватан сугышы фронтларында ни дәрәҗәдә батырлык күрсәтүе һәм нинди данга ия булуы турында юньле-башлы ишетеп тә белмидер. Безнең бабайлар тыйнак һәм горур булган шул, хәзергеләр кебек, алар күкрәкләрен фәлән юбилей, төгән юбилей медальләре белән бизәп яшәмәде. Әмма якташларыбызның батырлыгын бүгенге яшь буын, һәм киләчәктәгеләр нык белергә тиеш. Ватан алдында безнең бабаларның йөзе кызармаслык!

● 1941 елның октябре. Тупчы сугышчылар чигенә. А. Шайхет фотосы.

Михаил ЧЕРЕПАНОВ.
«Миллиард татар» челтәреннән. **Вахит ИМАМОВ** тәрҗемәсе.

● Мәскәү, Кызыл мәйдан. Октябрь, 1941 ел.

● Башкаланың Мәскәү елгасы аша салынган күперендә атлы патруль.

ЧАКМАГЫШТАГЫ

Башкортстанның Чакмагыш районында, район үзәгеннән 2-3 чакрым ераклыкта, борынгы Иске Калмаш шәһәрчеге бар. Бу урынны Кала-Тау дип тә атыйлар. Алтын Урда чәчәк аткан чорда биредә иске татар телендә, ягъни гарәп шрифтында укый-яза белгән, ислам динен тоткан халык яшәгән. Шушы тирәлектән табылган савыт-саба ватыклары, эш кораллары, ук очлары, 1340 елларга караган кабер ташлары моны дәлилли.

● **Марат Ахунов.** Илфир Котдусов фотосы.

Кала-Тау Алтын Урда белән бергә җимерелгән. Риваятьләр буенча, шәһәрчекне 1390 елларда Аксак Тимер тар-мар иткән. Явыз Иван җимергән, дигән фаразлар да бар. Бу урын әле ныклап өйрәнелмәгән, ләкин тарихчылар, җирле халык арасында кызыксыну уята.

Төбәк тарихын өйрәнүче Марат Ахунов Кала-Тауга бәйле кызыклы риваятьләр белән таныштырды. Алар халык телендә буыннан-буынга күчеп, бүгенге көнгә килеп җиткән.

Риваять буенча, 1391 елда Кала-Тау кирмәнен Аксак Тимер җимерә. Халык телендә ул Тимеркәй булып саклана. Тимеркәй Кала-Тауга килгән дә, гаскәр санын күбрәк күрсәтер өчен, ул һәр сугышчыга саламнан кеше кыяфәтендә өчәр карачкы ясарга кушкан. Төнлә ут яктысында болар күп күренгән. Шул рәвешле алар кирмәнгә кереп, халыкны кырган. Исән калганнары качып, хәзерге Чакмагышка нигез салган.

Кала-Тауга бәйле тагын бер кызыклы тарих.

– Элекке заманнарда Кала-Тау хәзинә эзләүчеләрне җәлеп иткән, – ди Марат Ахунов. – Чакмагыш авылында яшәүче фермер Илдус Шәрипов сөйләвенчә, аның бабасы Мостафа Гайнуллин 1870 елларда Казан артыннан, Казанбаш авылыннан килгән. 7 ел буе ул Чакмагышта көтүче булып эшләгән һәм шул гомер Кала-Тауда хәзинә эзләгән. Аның тырышлыгы юкка булмаган – ул монда алтын һәм көмеш хәзинәсе тапкан. Бу байлыкка ул Чакмагыш елгасының өске агымында җир сатып алган, яхшы йорт, хуҗалык корылмалары, кунакханә төзегән, ятим балалар өчен приют ачкан. Акчаның бер өлешен ул Уфада кибетләр төзүгә тоткан, киявенә – соңыннан Уфа миллионеры булып танылган Кәримовка кибетләр төзергә ярдәм иткән.

Марат Ахуновның 2012 елда Чакмагыш районы Болгар авылында яшәүче Рима Тимашевадан «Данлы кое» турында язып алган истәлеге бар:

«Олыкулның югары очыннан башлана торган чишмәне «Данлы кое», «Дару чишмәсе», «Әүлия чишмәсе» дип йөртәләр. Чишмә әүлия каберенең баш очыннан башлана. Борын заманнарда, авыру кешеләрне савыктыру өчен, Әүлия чишмәсенә алып барганнар», – дип сөйләгән Рима Тимашева.

«Данлы кое» турында тагын бер истәлек бар. «Элек бездә «Данлы кое» бар иде. Тозлыкуш белән Калмаш арасындагы урманда, Кала-Тауга терәлеп үк тора. Бөтен чирле-чорлы кешеләр шунда дәваланырга килгән. Дүртөйле яклары безнең авыл аша йөргәннәр. Сукыр, кул-аягы сызлаган гарип-гораба үтеп китә иде, дип сөйли иде безнең картинәй. Алпавыт Верегиннар шунда, кәеф-сафа корып ятар өчен, кирпечтән бер нәрсә дә төзеткән булган. «Данлы кое»ны шуңа да «Дару чишмәсе» дип тә йөртәләр. Чын исеме «Данлы кое» инде аның. «Данлы кое» чишмәсе әүлия зиратының баш очыннан чыга, диләр. Чишмә исемен дә шул әүлия исеме белән кушканнардыр инде», – дип сөйләгән Тозлыкуш авылыннан Фәнис Әмирханов.

Кала-Тауда Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының бер төркем галимнәре булып китте. Без Казан кунакларын озатып йөргән тарихчыларның берсе Илфир Котдусов белән сөйләшеп алдык.

«Аларның килүе әйбәт булды, сүз дә юк. Төбәкчеләрне җыеп, төбәк тарихын өйрәнү турында сөйләштек. Кушнаренкода конференция дә үткәрдек. Шушы көннәрдә Чакмагышта Башкортстанның күпчелек районнарыннан икътисадчылар җыелды. Аларның маршрутына без Кала-Тауны да керттек. Тарихчы Марат Ахунов белән икәү экскурсовод булып йөрдек.

Кала-Тау – тарихи яктан бик кызыклы урын. Аны Иске Калмаш шәһәрчеге дип тә атыйлар. Монда берничә чорны өйрәнергә була. IV-VI васырларда биредә мадьярлар (венгрлар) яшәгән. Уфадан алып Кама буена кадәр сузылган территория – борынгы мадьярлар җире. Элек башкортлар да үзләрен фин-угыр халыкларыннан чыккан, дип әйтә иде, ә соңыннан төркигә күчтеләр. VIII-IX гасырларда монда мадьярларның кара-якуп мәдәнияте хөкем сөрә. Аннан соң Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда чорлары китә.

Узган гасыр урталарында Кала-Тау янында 1347 елда куелган кабер ташы табыла. Ул хәзер Уфада, Раил Кузеев исемендәге Этнологик тикшеренүләр институтының Археология һәм Этнография музеенда саклана. Аның күчермәсе Чакмагыш музеенда да бар. Иң әһәмиятлесе шул – таш борынгы татар телендә язылган. Кушнаренко районында да шушындый ук таш бар. Ул 1342 елда, ягъни әкияти Куликово сугышына кадәр 38 ел алда куелган. Бу – Алтын Урданың чәчәк аткан чорына туры килә. Димәк, шул заманда Кала-Тау тирәсендә татар телле халык яшәгән.

Кала-Тау темасын күтәрүдә Марат Ахунов зур роль уйнады. Ул Кала-Тау турында риваятьләр туплады, мәкаләләр язды. Мин алтакта ясату идеясен бирдем, кешеләр җәлеп итәргә ярдәм итәм. Чакмагыш егетләре быел алтакта яздыртып куйды. Күптән түгел Кала-Тауда икътисадчылар булып китте, дидем. Казан тарихчылары да килде. Көз көне Кушнаренкодагы Даян Мурзин исемендәге Күп профильле көллият студентларын алып килергә ниятлим. Мин анда тарих укытам.

Кала-Таудан 50 метрлап ераклыкта тагын бер тау бар. Чакмагыш эшмәкәрләре шунда кирмән төзеп, тау чаңгысы шуа торган урын ясарга хыяллана. Кала-Тауның үзендә бернәрсә дә төзергә ярамый, чөнки ул тарихи тыюлык

● Илдар Габдрәфыйков. Фото «Татар-информ» архивыннан.

● Илнур Миргалиев. Фото «Татар-информ» архивыннан.

КАЛА-ТАУ

статусына ия. Янәшәдәге тауда аны эшләргә була. Тарих белән кызыксынып кына күп кеше килмәс. Әгәр монда ял итү урыны да булса, халыкны җәлеп итеп булыр иде».

Раил Кузеев исемендәге Этнологик тикшеренүләр институтының баш фәнни хезмәткәре Илдар Габдрәфыйков та Кала-Тау янында табылган 1347 елгы ташның иске татар телендә язылган булуын, Чакмагыш районында Алтын Урда чорыннан ук татар телле халык яшәгәнен әйтте.

– Кала-Тау янында табылган кабер ташы безнең институт музеенда саклана. Аны татар теленә Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге тарих институты галиме Илнур Миргалиев тәрҗемә итте. Ташның куелган елын да ул укып белде. Кайбер чыганакларда, нишләптер, һаман да 1442-1447 еллар дип күрсәтелә. Илнур Миргалиев аның һиҗри буенча 747 елга, ягъни безнеңчә 1346-1347 елларга караганын ачыклады. Таш иске татар телендә язылган. Сүзләрнең фонетикасы да татар теленә якын. Шуңа нигезләнеп, без «Кала-Тауда, ягъни хәзерге Чакмагыш районында, Алтын Урда чорыннан ук татар телле халык яшәгән», дип әйтәбез, – диде галим.

Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Алтын Урда һәм татар ханлыкларын өйрәнү үзәге җитәкчесе Илнур Миргалиев Кала-Тау галимнәр тарафыннан аз өйрәнелгәнен һәм аннан яңа ачышлар килеп чыгу ихтималын белдерде.

– Май аенда без, Башкортстандагы төбәк тарихын өйрәнүчеләр чакыруы буенча, Кушнаренко, Чакмагыш, Чишмә районнарын йөреп кайттык. Сәфәрнең төп максаты – Кала-Тау шәһәрчегеен барып карау иде, – диде Илнур Миргалиев. – Җирле активистлар Рамил Хәбиров, Марат Ахунов, Илфир Котдусов, Рамил Гыйбадуллин аны өйрәнүгә, халыкка танытуда зур көч куя. Алар бу урынны безгә дә күрсәтергә теләде. Без, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының бер төркем галимнәре, Кала-Тауны барып күрдек. Ул бик матур урында, тау башында урнашкан. Шулай төпләнү борынгы шәһәрчекләргә хас.

XIX гасыр азагында ул җирләргә Верегин фамилияле алпавытлар хуҗа булган. Алар Кала-Тауда сакланган таш биналарны җимерттереп, ташларын сыер, дуңгыз, ат абзарлары төзелешендә кулланган. Бүген туфрак өемнәре, чокырлар рәвешендә кирмәннең нигез урыннары гына күренеп тора.

Безнең тирәлектә борынгы таш биналар Алтын Урда чорына гына хас. Болгарда сакланган биналар да шул чорга карый. Гадәттә, таштан йә мәчет, йә мунча, йә төрбә төзегәннәр. Чишмә районындагы, Болгардагы төрбәләргә карап, Кала-Тауда нинди биналар булганын күз алдына китерергә мөмкин.

Кала-Тау – Алтын Урда дәүләте Агыйдел олысының берәр административ берәмлеге булгандыр, дип уйлыйм. Анда 10 меңлек Түмән гаскәре дә утырган булуы мөмкин. Марат Ахунов халык телендә сакланган риваятьләрне туплап, китапка кертте. Бер риваятьтә Кала-Тауның сугышта җимерелгәне, ә икенчесендә Тимеркәй (Аксак Тимер) тарафыннан тар-мар ителгәне, ә халкы Чакмагышка күчеп утырганы әйтелә. Аксак Тимер бу тирәләргә үзе килгәнме-юкмы, мәгълүм түгел, ләкин Кондырча елгасы буендагы 1391 елгы сугыштан соң, аның гаскәре 26 көн буе бу тирәләрне талаганы билгеле. Шәһәрчек Явыз Иван тарафыннан җимерелүе турында да риваять бар. Аның тарихын ныклап өйрәнергә кирәк.

Кала-Тау археологлар тарафыннан бик аз өйрәнелгән – «капка» турысы гына казылган. Кызганыч, аның археологик табылдыклары буенча отчетлары да басылмаган. Безгә фактик материаллар җитми. Риваятьләр нигезендә генә төпле фикер йөртеп булмый. Кала-Тауны археологик яктан өйрәнергә кирәк. Ул безгә, һичшиксез, яңа ачышлар китерәчәк. Бәлки, язма чыганаклар да килеп чыгар.

Кала-Тау янында табылган кабер ташы Үзбәк ханның улы Җанибәк чорына карый. Таш Күкләр исемле шәхескә куелган. Әлегә бу урында башка кабер ташлары табылмаган. Алар төзелештә кулланылып беткән булырга мөмкин. Җирле халык бу шәһәрчекне белә. Кала-Тауны бик борынгы заманнар белән бәйләүчеләр дә бар, ләкин таш биналарның эзләре Алтын Урда чорына карый.

Р.КАЮМОВ.

● Кала-Тауга сәфәр кылучылар төркеме. Аларны озатып йөрүчеләрдән Илфир Котдусов сулдан беренче, уң якта алда басып торучы – Марат Ахунов.

ТАТАР ҖАЙДАКЛАРЫ

● **Башкорт кантонындагы обер-офицер, 1829-1838.** А.В.Висковатов эше.

● **«Башкорт» җайдагы. 1829-1838.** Ж.Ф.Дюбуа.

(Дәвамы. Башы 38, 39 нчы саннарда).

Наполеонга каршы 1805-1807 еллардагы кампаниядә катнашучылар:

1.Походтагы йөзбашы Габделхалик Шәрип углы Айдаров – 1836 елда, формуляр төзегән чакта - 54, ә 1805 елда 25 яшьтә булган), Мәчти авылыннан (Актаныш). 1807 елда 3 нче «башкорт» полкы составында француз гаскәрләренә каршы походта һәм яуларда катнаша.

2. Дистанция башлыгы, йөзбашы Батырша Шәрип улы Шәрипов – 37 яшьтә, Чүри авылыннан (Актаныш). 1807 елда 19 нчы «башкорт» полкы составында француз гаскәрләренә каршы походта була.

3.Гаскәри хорунжий Гали Атнагол улы Чүриев – 28 яшьтә, Әтәс авылыннан (Актаныш). 1807 елда хәрби походларда була.

4.14 нче класстагы йорт старшинасы Идрис Сөеш улы Якупов – 40 яшьтә, Оргыды авылыннан (Тукай). 1807 елда 3 нче «башкорт» полкы составында французларга каршы походта һәм яуларда катнаша.

5. Гаскәри есаул Габделҗаббар Габделҗәлил улы Моратов – 43 яшьтә, Тулбай авылыннан (Минзәлә). 1807 елда 19 нчы полк белән походларда була.

6. Зауряд-есаул Зөбәер Өметбай улы Мәчтиев – 30 яшьтә, Чынык авылыннан (Актаныш). 1807 елда 19 нчы полк белән походларда катнаша.

7. Зауряд-йөзбашы Исламхуҗа Иркәш улы Исмәнаев – 30 яшьтә, Мортышбаш авылыннан (Сарман). 1807 елда 3 нче «башкорт» полкы составында, шулай ук 1812-1814 еллардагы походларда һәм яуларда катнаша.

8. «Башкорт» Нәзир Зәбиров – 31 яшьтә, Әлмәтмулла авылыннан (Сарман).

9. Йорт старшинасы, зауряд-есаул Әхтәри Мөгътәсар улы Хөсәенов – 26 яшьтә, Солтангол авылыннан (Актаныш). 1807 елда французларга каршы походта, 1812-1814 елларда 19 нчы «башкорт» полкы белән яуларда катнаша (Ә.Әсфәндияров, 399 б.).

10. Зауряд-хорунжий Туйхуҗа Тойгын улы Барысов – 27 яшьтә, Кадермәт авылыннан (Актаныш). 1807 елгы походларда катнаша.

11. Зауряд-есаул Габдрәшит Әбсәлам улы Айтуганов – 28 яшьтә, Чалманарат авылыннан (Актаныш). 1807 елгы походларда катнаша.

12. Йорт старшинасы һәм гаскәри старшина Хөсәен Акай улы Зөбәеров – (21 яшьтә), Зөбәер авылыннан. 1807 елга походларда була һәм французлар белән яуларда катнаша. (Ә.Әсфәндияров, 326 б.).

13. Старшина ярдәмчесе, зауряд-йөзбашы Шәнгәрәй Акай улы Зөбәеров – 21 яшьтә, Зөбәер авылыннан (күрәсең, ул Хөсәен белән игезәк булгандыр; ә аларга бабай тиеш Зөбәер картны хәзерге Актаныш районында үз исемендәге авылны нигезләүче дип санарга кирәк). 1807 елда 3 нче «башкорт» полкы составында походта була һәм яуларда катнаша (Ә.Әсфәндияров, 326 б.).

14. Гаскәри старшина Илкәй Гаделша улы Әрәптанов – 30 яшьтә, Бикбау авылыннан (Минзәлә). 1807 елда 3 нче полк составында французларга каршы походта һәм яуларда катнаша.

15. Старшина ярдәмчесе, есаул Габделкадыйр Нигъмәтулла улы Кошаев – 28 яшьтә, Имән авылыннан (Сарман). 1807 елда 19 нчы полк белән «Пруссия» походында була.

16. Зауряд-есаул Хәйбулла Зәйнибәшир улы Айманов – 27 яшьтә, Имән авылыннан (Сарман). 1807 елда 19 нчы полк белән походларда була.

17. Гаскәри старшина Фәтхулла Ишәй (Ишмөхәммәт-?) улы Баймурзин – 34 яшьтә, Сөлек авылыннан (Сарман). 1807 елда 3 нче «башкорт» полкы составында походларда һәм яуларда катнаша.

18. Йорт старшинасы, зауряд-йөзбашы Ярмөхәммәт Әлмөхәммәт улы Ибраев – 32 яшьтә, Метрәй авылыннан (Мөслим). 1807 елда 3 нче полк белән походларда һәм яуларда катнаша.

19. Старшина ярдәмчесе, зауряд-йөзбашы Гыйсмәтулла Мөэминкул улы Шәрипов – 29 яшьтә, Мәлләтамак авылыннан (Мөслим). 1807 елда 20 нче полк составында «француз» походларында катнаша.

20. Йорт старшинасы, зауряд-есаул Ардуан Гадел улы Яугилдин – 26 яшьтә, Аеш авылыннан (Актаныш). 1807 елда 19 нчы полк белән походларда.

21. Гаскәри старшина Зөбәер Мөҗәй (Мөҗәһит) улы Әбсәламов – 29 яшьтә, Иске Әлемнән (Актаныш). 1812 елда 19 нчы «башкорт» полкы составында сугыша (Ә.Әсфәндияров, 266 б.).

22. Зауряд-йөзбашы Бикташ Габделкадыйм улы Ишмәтов (Ишмөхәммәтов) – 28 яшьтә, Яңа Әлем авылыннан (Актаныш). 1807 елда 20 нче полк белән походларда була.

1812 елгы Ватан сугышында һәм 1813-1814 елларда Европа походында катнашучылар

Беренче йорт:

1.14 нче классы походтагы старшина Габделмәннәф Сөеш улы Сарбулатов (мөгаен, Сарыйбулатовтыр; «сарый» сүзе «бәхетле» дигән төшенчәне аңлаткан) – 1812 елда 26 яшьтә булган, Олы Имәннән (Актаныш). 1812-1814 елларда 5 нче «башкорт» полкы белән төп армия составында французларга каршы яуларда һәм чит ил походларында катнаша. 1834 елда аңа офицер һәм дворян дәрәҗәләре бирелә (Ә.Әсфәндияров, «Аулы...», 439 б.)

2. Зауряд-йөзбашы Корбангали Бикташ улы Туктаров – 20 яшьтә, Сәфәрдән (Актаныш). 1812-1814 елларда төп армиядә 6 нче «башкорт» полкы составында барча походларда була (Ә.Әсфәндияров, 392 б.).

3. Зауряд-хорунжий Габидулла Мөсәгыйт улы Миндәев – 20 яшьтә, Байсардан (Актаныш). 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында төп армия белән походларда була.

4. «Башкорт» Габделгаффар Бикташев – 29 яшь, Сәфәрдән. 1814 елда армияда.

5. «Башкорт» Мөрсәлим Сәлимҗанов – 28 яшь, Сәфәрдән. 1814 елда армияда.

6. «Башкорт» Габделвәли Габделмаликов – 26 яшь, Сәфәрдән. 1814 елда армияда.

7. «Башкорт» Исмәгыйл Исламгулов – 26 яшь, Олы Имәннән (Актаныш). 1814 елда армияда.

8. «Башкорт» Ямангол Нәҗәргулов – 27 яшь, Олы Имәннән. 1814 елда армияда.

9. «Башкорт» Әрдәшир Идрисов – 28 яшь, Яхшыйдан (Актаныш). 1814 елда армияда.

Икенче йорт:

10. Йорт старшинасы, зауряд-йөзбашы Габделнасыйр Күзәш улы Чүриев – 23 яшьтә, Чүри авылыннан (Актаныш; бабасы Чүри үз исемендәге авылны нигезләгән). 1812-1814 елларда 6 нчы «башкорт» полкы белән барча походларда була.

11. Зауряд-хорунжий Хәйбулла Ишкилде улы Шыгаев – 24 яшьтә, Мәчти авылыннан (Актаныш). 1812-1814 елларда 5 нче полк составында төп армияда була, Европа походларында һәм яуларда катнаша.

12. Зауряд-хорунжий Шәмсетдин Сагындык улы Сөләйманов – 25 яшьтә, Күҗәкә авылыннан (Актаныш). 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында төп армияда, хәрби походларда була.

13. «Башкорт» Хисаметдин Мөрсәлимов – 31 яшьтә, Әтәс авылыннан (Актаныш). 1814 елда армияда була.

14. Гаскәри старшина Габдессәлам Габдрәшитов – 29 яшьтә, Күҗәкә авылыннан. Кайсы полкта яу йөргүе билгеле түгел, әмма 14 нче классы түрә һәм дворян дәрәҗәсе белән бүләкләнүе мәгълүм (Ә.Әсфәндияров, «Аулы...», 359 б.).

15. «Башкорт» Мөхәммәтгали Батырша улы Шәрипов – Күҗәкә авылыннан. 1813 нче елда армияда (Ә.Әсфәндияров, 360 б.).

Өченче йорт буенча мәгълүмат табылмаган.

Дүртенче йорт:

16. «Башкорт» Габделхалик Габдиев – 35 яшьтә, Күзкәй авылыннан (Тукай районы). 1812 елда армияда була.

17. «Башкорт» Мөхәммәтрәхим Баязитов – 33 яшь, Күзкәйдән. 1812 елда армияда.

18. «Башкорт» Миңлекәй Батраев – 34 яшьтә, Гөлек авылыннан (Минзәлә). 1812 елда армияда.

Бишенче йорт:

19. Йорт старшинасы, зауряд-йөзбашы Миндәй Габделҗәлил улы Күчемов – 21 яшьтә, Байлар авылыннан (Минзәлә). 1812-1814 елларда 6 нчы «башкорт» полкы составында төп армия белән походларда була.

20. Зауряд-есаул Әлмәкәй Атнакай улы Сатыев – 26 яшьтә, Тулбайдан (Минзәлә). 1812-1814 елларда 5 нче полк составында төп армияда һәм походларда була, яуларда катнаша.

21. «Башкорт» Бикчәнтәй Искәндәров – 33 яшь, Байлардан (Минзәлә). 1812 елда армияда була.

22. «Башкорт» Мөхәммәтгали Ярмөхәммәтов – 33 яшь, Байлардан. 1812 елда армияда.

23. «Башкорт» Сөендек Ишмөхәммәтов – 29 яшь, Байлардан. 1812 елда армияда.

24. «Башкорт» Сәйфулла Нигъмәтуллин – 33 яшь, Хуҗәмәттән (Минзәлә). 1812 елда армияда.

25. «Башкорт» Туйчин Таһи-

ЕВРОПАДА

ров – 29 яшьтә, Усай авылыннан (Минзәлә). 1812 елда армияда.

26. «Башкорт» Бикмөхәммәт Мәсәгутов – 33 яшь, Усайдан. 1812 елда армияда була.

Алтынчы йорт:

27. Старшина ярдәмчесе, зауряд-йөзбашы Имәнгол Мөхәммәтрәхим улы Мөслимов – 20 яшьтә, Чат авылыннан (Актаныш). 1812-1814 елларда 6 нчы «башкорт» полкы составында төп армияда походларда була.

● **Мәскәүнең тарихи музеена куелган «Башкорт» сыны.** Фарфор. 1860-1880 еллар.

28. Зауряд-йөзбашы Гайнулла Мәсәгут улы Сәйтәков – 24 яшьтә, Бикчәнтәй авылыннан (Актаныш). 1807 елда – 19 нчы «башкорт» полкы, ә 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында хәрби походларда була.

29. Зауряд-йөзбашы Ногманнасыйр Мәдияр улы Бикчурин – 30 яшьтә, Бикчәнтәйдән. 1812-1814 елларда 5 нче «башкорт» полкы составында төп армияда французларга каршы яуларда сугышкан, чит илләрдәге походларда катнаша.

30. Зауряд-йөзбашы Исламгол Өметбай улы Мәчтиев – 20 яшьтә, Чынык авылыннан (Актаныш). 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында төп армияда һәм походларда була, (абыйсы Зөбәер 1807 елда Пруссиягә ясалган походта катнаша).

31. «Башкорт» Төхфәтулла Кылычев – 28 яшь, Усы авылыннан (Актаныш). 1812 елда армияда була.

32. «Башкорт» Фәйзулла Габитов – 25 яшь, Усыдан. 1812 елда армияда.

33. «Башкорт» Бәхтияр Мәдияр улы Әитов – Бикчәнтәй авылыннан (Актаныш). 1806-1807 елларда Пруссия кампаниясендә һәм 1812 елда 19 нчы «башкорт» полкы составында сугыша (Ә.Әсфәндияров, «Аулы...», 302 б.).

Җиденче йорт:

34. Йорт старшинасы һәм гаскәри старшина Габделлатыйф Әбсәлам (дөресе - Габдессәлам) улы Кормашев – 31 яшьтә, Нөркәй авылыннан (Сарман районында; аның әтисе Габдессәлам әле 1800 елларда ук Кормаш авылыннан Нөркәйгә күчеп урнаша, Күктәкә һәм Мусабай Завод авыллары тирәсендә бик күп җирләр били, сәүдә белән шөгыльләнә). 1812-1814 елларда 5 нче «башкорт» полкы составында төп армияда һәм чит ил походларында катнаша, канлы яуларда каһарманлык күрсәтә.

35. «Башкорт» Сабит Габдрәшитов – 29 яшьтә, Нөркәйдән. 1814 елда армияда була.

36. «Башкорт» Габдулла Өметбаев – 26 яшьтә, Яңа Әхмәтабыз (Әхмәт) авылыннан (Сарман). 1814 елда армияда.

37. «Башкорт» Исмәгыйл Ибраһимов – 33 яшьтә, Теләнче Тамактан (Тукай районында). 1814 елда армияда була.

Сигезенче йорт:

38. Йорт старшинасы, зауряд-есаул Гыйбадулла Әмин улы Урмәкәев – 25 яшьтә, Әлмәтмулла авылыннан (Сарман). 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында төп армияда һәм чит ил походларында була.

39. Старшина ярдәмчесе, зауряд-есаул Фәйзулла Монасыйп улы Уразмәтов – 24 яшьтә, Мортыштамак авылыннан (Сарман). 1812-1814 елларда 5 нче полк составында төп армияда французларга каршы яуларда һәм чит ил походларында була.

40. Зауряд-хорунжий Миндәй Исхак улы Тукбаев – 32 яшьтә, Әлмәтмулла авылыннан. 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында походларда була.

41. Урядник Гыйбадулла Ямангулов – 21 яшьтә, Карамалы авылыннан (Мөслим). 1812-1814 елларда 5 нче полк составында французларга каршы яуларда һәм чит ил походларында катнаша.

42. «Башкорт» Фәйзулла Габидуллин – 28 яшьтә, Әлмәтмулла авылыннан. 1812 елда армияда була.

43. «Башкорт» Кадыйр Сәмигуллов – 31 яшьтә, Сарайлы Бикмәт авылыннан (Сарман районында). 1812 елда армияда була.

Тугызынчы йорт:

44. Зауряд-йөзбашы Габделсаттар Габделлатыйф улы Гомәров – 25 яшьтә, Такталачык авылыннан (Актаныш). 1807 елда – 3 нче «башкорт» полкы, 1812-1814 елларда 5 нче полк составында походларда һәм яуларда катнаша (Ә.Әсфәндияров, 415 б.).

45. «Башкорт» Гобәйдулла Зөлкәрнәев – 29 яшьтә, Югары Такталачык авылыннан (Актаныш). 1812 елда армияда була.

Унынчы йорт:

46. Зауряд-есаул Габделмоталлап Габделкәрим улы Исәнбаев – 27 яшьтә, Уразай авылыннан (Актаныш). 1812-1814 елларда 5 нче полк составында французларга каршы яуларда һәм чит ил походларында катнаша.

47. «Башкорт» Ибраһим Ильясов – 31 яшьтә, Әҗәкүл авылыннан (Актаныш). 1812 елда армияда була.

48. «Башкорт» Хәбибулла Гаделшин – 25 яшь, Әҗәкүлдән. 1812 елда армияда.

49. «Башкорт» Габделваһап Сөендеков – 31 яшь, Куян авылыннан. 1812 елда армияда.

50. «Башкорт» Габделлатыйф Габитов – 30 яшь, Уразайдан. 1812 елда армияда.

51. «Башкорт» Габделмәҗит Габдуллов – 27 яшь, Уразайдан. 1812 елда армияда.

52. «Башкорт» Мөхәммәтша Батыршин – 28 яшьтә, Ирмәш авылыннан (Актаныш). 1812 елда армияда.

53. «Башкорт» Кадергол Туишев – 30 яшьтә, Шәриптән (Актаныш). 1812 елда армияда була.

Уберенче йорт:

54. Зауряд-йөзбашы Котлыяр Яркәй улы Аканов (?) – 22 яшьтә, Мерәс авылыннан (Актаныш). 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында походларда була.

55. «Башкорт» Габделшәрип Монасыйпов – 30 яшь, Югары Актанышбаш авылыннан. 1812 елда армияда була.

56. «Башкорт» Искәндәр Ишмәнов – 30 яшьтә, Тыңламас авылыннан (Актаныш). 1814 елда армияда.

57. «Башкорт» Биктимер Юлдашев – 29 яшь, Тыңламастан. 1813 елда армияда.

Уникенче йорт:

58. «Башкорт» Фазулла Һидаин – 36 яшьтә, Яңа Богадыдан (Актаныш). 1812 елда армияда була.

59. «Башкорт» Габделнасыйр Рәфыйков – 33 яшь, Яңа Богадыдан. 1814 елда армияда.

60. «Башкорт» Габделтаһир Габделҗәлилов – 29 яшь, Иске Богадыдан. 1813 елда армияда.

61. «Башкорт» Габделхәбир Дәүләтбаев – 28 яшь, Кадермәттән (Актаныш). 1812 елда армияда була.

62. «Башкорт» Габделвахит Габделкәримов – 27 яшь, Кадермәттән. 1812 елда армияда.

63. «Башкорт» Габделбәшир Аднагулов – 27 яшь, Кадермәттән. 1812 елда армияда.

64. «Башкорт» Габделшәриф Йөзекәев – 28 яшь, Солтангол авылыннан (Актаныш). 1812 елда армияда була.

65. «Башкорт» Әлби (Галибай) Вәлитов – 27 яшьтә, Солтанголдан. 1813 елда армияда.

66. «Башкорт» Сөләйман Сабитов – 23 яшьтә, Солтанголдан. 1814 елда армияда.

Уноченче йорт:

67. Зауряд-йөзбашы Габделкадыйр Миңлебай улы Канбаров (Хәмбәров-?) – 20 яшьтә, Карт авылыннан (Актаныш). 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында төп армияда һәм чит илләргә походларда була.

68. Зауряд-хорунжий Миңлегол Котлымәт (Котлыгмөхәммәт) улы Канбаров – 26 яшьтә, Суыксу авылыннан (Актаныш; боларның бабасы бер үк кеше булу мөмкин). 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында төп армияда һәм чит илләргә походларда була.

69. Урядник Фәтхулла Ильясов – 18 яшьтә, Суыксу авылыннан. 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында төп армияда һәм чит илләргә походларда була.

70. «Башкорт» Мөхәммәтрәхим Мөсәгыйтов – 30 яшь, Шәбез авылыннан (Актаныш). 1813 елда армияда.

71. «Башкорт» Бикташ Минләшев (Миндәшев-?) – 28 яшь, Шәбездән. 1812 елда армияда була.

Ундүртенче йорт:

72. Йорт старшинасы, зауряд-хорунжий Хәйбулла Ильяс улы Иләмәнев – 20 яшьтә, Җияш авылыннан (Актаныш). 1812-1814 елларда 5 нче полк составында төп армияда һәм чит илләргә булган походларда катнаша.

73. Зауряд-есаул Габделгалим Габдекәй улы Теләкәев – 25 яшьтә, Иске Гәрәй авылыннан (Актаныш). 1812-1814 елларда 5 нче полк составында төп армияда һәм чит илләргә походларда катнаша.

74. «Башкорт» Габделкаһир Әбдекәев – 28 яшьтә, Иске Гәрәйдән. 1814 елда армияда була.

75. «Башкорт» Каһарман Тимеркәев – 26 яшьтә, Иске Гәрәйдән. 1814 елда армияда.

76. «Башкорт» Моратбакый Сөендеков – 30 яшь, Җияштән. 1814 елда армияда.

77. «Башкорт» Фәйзулла Сөендеков – 27 яшьтә, Җияштән (соңгы икесенең бертуганнар булуы да мөмкин). 1813 елда армияда була.

78. «Башкорт» Габидулла Яманголов – Иске Кормаш авылыннан (Актаныш). 1812-1814 елларда 5 нче «башкорт» полкы составында яуларда һәм Европага походта катнаша (Ә.Әсфәндияров, «Аулы...», 369 б.).

Унбишенче йорт:

79. Зауряд-йөзбашы Нариман Миндәй улы Сар(ый)булатов – 20 яшьтә, Сәүз авылыннан (Иске һәм Яңа Өшәр крестияннары XVIII гасыр азагында Актаныш районында оештырган яңа авыл. 1816 елда анда 120 кеше яшәгән. Хәзер авыл юк инде). 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында төп армия_да һәм чит илләргә походларда була.

80. Зауряд-йөзбашы Гаделша Дәүләтбай улы Купаев (?) – 20 яшьтә, Әҗби авылыннан (Актаныш). 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында төп армияда һәм чит илләргә походларда була.

81. «Башкорт» Мәнди Габитов – 28 яшь, Сәүздән. 1814 елда армияда.

82. «Башкорт» Рәхимкол Нәдергулов – 28 яшьтә, Әҗби авылыннан. 1814 елда армияда була.

Уналтынчы йорт:

83. Походтагы старшина, полк хорунжие Нигъмәтулла Якуп улы Юзиев – 27 яшьтә, Әлмәт авылыннан (Мөслим). 1807 елда француз гаскәрләренә каршы походларда һәм яуларда, 1812-1814 елларда 5 нче полк составында төп армияда һәм чит илләргә походларда һәм яуларда катнаша, 1812 ел һәм Парижны 1814 елның 19 мартында алу истәлегенә булдырылган көмеш медальләр, алардан тыш әле орден белән дә бүләкләнә (Дубровский А. Наш край: Нижнее Прикамье, Казань, 2007. 451 стр.).

84. «Башкорт» Төхфәтулла Фәйзуллин – 36 яшьтә, Табанлыкүл авылыннан (Актаныш). 1813 елда армияда була.

85. «Башкорт» Ардуан Рәфыйков – 29 яшь, Әгъбәс авылыннан (Актаныш). 1813 елда армияда.

86. «Башкорт» Әхтәм Ихсанов – 27 яшь, Әгъбәстән. 1813 елда армияда.

87. «Башкорт» Гомәр Тимеров – Сәет авылыннан (Мөслим). 1813 елда армияда һәлак була (Ә.Әсфәндияров, 539 б.).

88. «Башкорт» Миндәй Тимеров – Сәет авылыннан. 1814 елда армияда.

Унҗиденче йорт:

89. Зауряд-есаул Ногъман Хәмит улы Туйкин – 22 яшьтә, Түке авылыннан (Актаныш). 1812-1814 елларда 5 нче «башкорт» полкы составында төп армияда һәм чит илләргә походларда була.

90. Өлкән писарь Сәетбаттал Сәйфуллин – 20 яшьтә, Бикбау авылыннан (Минзәлә). 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында төп армияда һәм чит ил-ләргә походларда була (Ә.Әсфәндияров, «Аулы...», 118 б.).

(Ахыры киләсе санда).

Вахит ИМАМОВ.

«ИДЕЛ-УРАЛ»

Төркиядә яшәгән күренекле Казан татарларыннан калган тарихи әдәби мирасны һаман җитәрлек дәрәҗәдә табып-өйрәнеп бетерә алмыйбыз әле. Мәсәлән, XX гасыр уртасында Мәҗит Сакмар тарафыннан чыгарыла башлаган, ләкин бүгеннәрдә генә очраклы рәвештә кулыма килеп кергән «Идел-Урал» исемле журнал турында, бик күпләр кебек, минем дә ишеткәнем юк иде. Әлеге хәбәрне биргән һәм материаллар белән тәэмин иткән азәрбайҗан галим-эзтабарларыннан «Чапар» журналының баш редакторы Дилкам Әхмәд әфәндегә рәхмәт.

«Идел-Урал» журналы 1955 елның май аенда Истанбулда Османбәй матбагасында төрек һәм инглиз телләрендә бер мәдәни җыентык – айлык «культур мәҗмугасы» рәвешендә чыга башлый. Хуҗасы һәм баш редакторы булып Мәҗит Сакмар әфәнде (1888-1978) тора. Ни кызганыч, шушы көнгә кадәр М.Сакмар хакында да мәгълүматларыбыз бик чикле, Кырым татарларының Төркиядә чыккан «Әмәл» журналының 1978 елгы санында бирелгән некрологта аның Казанга бәйле Сакмар авылында (хәзерге Оренбург өлкәсендә) тууы, 1905 елда Истанбулга күчеп килүе, хәрби мәктәпне бетергәч, офицерлар хәзерли торган уку йортында, аннан соң хәрби Академиядә белем алуы хәбәр ителә. Балкан явында, аннары Беренче бөтендөнья сугышында катнашуы, төрек халкының милли-азатлык көрәшендә үзеннән өлеш кертүе турында әйтелә. Төркия армиясендә беренче һава көчләре оешмасын коручылардан булган М.Сакмар хәрби министрлыкта һәм генераль штабта хезмәт итеп, полковник дәрәҗәсендә лаеклы ялга чыккан [İdil-Ural Millî Merkezi Başkanı Mecit Sakmar, 1978, s. 16]. Безнең мәгълүматларыбыз буенча, 1943 елда Генштабта хезмәт иткән вакытта «Һава географиясе» (Hava Cografyası; Ankara) исемле бер китап та бастырган булган. 1954 елдан алып вафатына кадәр Гаяз Исхакыйдан мирас булып калган «Идел-Урал милли мәркәзен» җитәкләгән. Хатыны Алия ханым (1902-1978) да актив иҗтимагый тормыш алып барган, уллары профессор Әхмәт Ата Сакмар (1941-2021), адвокат һәм галим буларак, зур дәрәҗәләргә ирешкән, халыкара хокук һәм дипломатия темалары буенча Европада һәм Төркиядә китаплар бастырган.

Монда кыскача гына «Идел-Урал милли мәркәзе» идарәсенең ни сәбәпле М.Сакмарга бирелүе турында да әйтеп китү урынлы булыр. Яшь япон тикшеренүчесе Р.Оно 2011 елда очраклы рәвештә букинистларда сакланып калган бер уникаль коллекция тапкан һәм бу хакта язып та чыккан иде [Ono, 2013]. Бу табылдык тупланмада, нигездә, мөһаҗирлектә яшәгән үзбәк зыялысы доктор Габделвәһаб Октайга килгән (1904-1968) хатлар булып, алар арасында Г.Исхакыйның соңгы көннәре белән бәйле язышмалар безнең өчен аеруча әһәмияткә ия.

Кызы Сәгадәт Чагатайның әтисенең сихәтләге, аңа бирелгән дарулар, аны ничек каравы турында Г.Исхакый белән дус булган Г.Октайга хәбәр биреп баруы Габделвәһаб әфәнденең Төркиядәге бик күп мөһаҗирләрнең «үз врачы» булуын күрсәтеп тора. Аңа язылган хатлар арасында Г.Исхакыйның ярдәмчесе булган Мирхуҗа Әрәлинең (Мирхуҗа Хәсән Әрәли (1896-1958) – генерал. Уфада мәдрәсәдә һәм гимназиядә белем алган. 1915 елдан Беренче бөтендөнья сугышында катнашкан, 1932 елда генерал-майор чины алган, Кызыл Армиянең 60 нчы һәм 275 нче дивизияләре белән идарә иткән. 1941 елда немецларга әсир төшкәч, туган илгә кайтмаган, 1949 елда Төркиягә килгән һәм Г.Исхакый янында эшләгән) 7 июльдә, ягъни Г.Исхакыйның вафатына 15 көн кала, язылган хатында исә әдипнең милли эшләр белән соңгы көннәренә кадәр шөгыльләнүе белдерелә һәм үз урынына «Идел-Урал милли мәркәзен» җитәкләрдәй кеше табарга тырышуы аңлашыла. Бу урынга беренче кандидат буларак, танылган инженер-нефтьче Кәмал Локман (Кәмал Локман (1899-1976) Казакъстанның Казалы шәһәрендә туган, башлангыч белемне шунда алганнан соң, гаиләсе белән Госманлы Төркиясенә күченгән. Урта мәктәпне бетергәч һәм армия хезмәтен тәмамлагач, Франциягә киткән, Гренобль политехника институтында, аннан соң Страсбургта нефтьчелек буенча югары уку йортын тәмамлаган (1927). 1929 елда Төркиягә кайтып, төрле дәүләт оешмаларында нефтьчелек буенча эшләгән, аеруча җир асты файдалы казылмаларын эзләү өлкәсендә фәнни эшләр алып барган һәм Төркиядә нефть сәнәгате формалашуга әһәмиятле өлеш керткән) күрсәтелә, ләкин Төркиядә закон буенча дәүләт чиновникларына иҗтимагый оешмалар белән җитәкчелек итәргә ярамаганга, бу кандидатура төшеп кала, аннан соң Нурулла Ата (Нурулла Ата (1887/88-1974), педагог. Самарада туган, 1909 елда Истанбулга килеп белем ала һәм башлангыч сыйныф укытучысы дипломына ия булган, 1913 елдан мәктәптә укыта башлаган. Армиядә хезмәт иткәннән соң, Кавказда, Азәрбайҗанда укыткан, 1923 елдан яңадан Истанбулга кайтып, профессиясе буенча эшләгән, 1952 елда пенсиягә чыкса да, төрле мәктәп һәм мәгариф оешмаларында хезмәт иткән) кандидатурасы килә, тик ул икеләнүен белдергәч, отставкадагы полковник Мәҗит Сакмарга мөрәҗәгать итәләр һәм ризалыгын алалар [Ono, 2013, s. 572]. Биографиясеннән күренгәнчә, М.Сакмар «Идел-Урал» журналын Гаяз Исхакыйдан Төркиядәге татар милли хәрәкәте җитәкчелеге идарәсен үз кулына алыр-алмас чыгара башлаган дияргә була: журналның 1 нче саны 1955 елның 19 маенда басыла, әгәр аны чыгару өчен рәсми язышмаларны, редакция портфелен туплау чорын искә алсак, Г.Исхакыйның вафатыннан (22 июль, 1954) соң узган вакыт шуңа туры килә. Моны исбатлый торган бик тә әһәмиятле тагын бер чыганак бар: ул да булса, Г. Исхакыйның вафатыннан соң чыккан «Милли мөҗаһит вә милли әдип Гаяз Исхакый» исемле җыентык [Milli Mücahit, 1955]. Истанбулда 1955 елда Осман бәй матбагасында басылган 49 битлек әлеге китапчыкның алгы битенә болай дип язылган: Бу – «Идел-Урал» мәҗмугасының беренче санына кушымтадыр. Мәҗмуга белән бергә бирелер, аеруча акчага сатылмас». Мәҗмуганың тышлыгында «Гаяз Исхакыйның соңгы рәсеме» куелган, икенче биттә рәхмәт сүзләре язылган: әдипнең вафатыннан соң телеграмма җибәреп, хат юллап, кайгы уртаклашкан Финляндия, Америка, Япония, Төркия, Европа илләрендәге дусларына, Украина, Белоруссия, Польшадагы фикердәшләренә редакция рәхмәт белдерә, диелгән. Җыентыкны М.Сакмарның «Беренче тәэсир» исемле язмасы ачып җибәрә, анда ул әдип белән беренче мәртәбә 1911 елда Истанбулның Нуры Госмания мәчете буендагы бер кунакханәдә очрашуын әйтә, «Йосыф Акчура белән икесен күргәндә алган тәүге тәэсирем гомер буе үзгәрмәде, 44 елдан соң яңадан күрешкәндә дә гел шулай калган кебек тоелды», дип яза автор. «Бер мөҗаһитнең тормышы» исемле икенче язманың авторы М.Әрәли Исхакыйның биографиясен, язучылык һәм журналистлык эшчәнлеген өч өлешкә бүлеп, укучыларга шактый җентекле мәгълүмат бирә. Өченче язма – «Гаяз Исхакый» – Кавказ эмигрантларыннан Сәид Шамил (Мөхәммәд Сәид Шамил (1901-1981) – Кавказның атаклы шәхесе Шәех Шамилнең оныгы, күренекле җәмәгать эшлеклесе, Кавказ мөһаҗирләренең лидеры) тарафыннан язылган. Аннан соң Азәрбайҗанның бөек каһарманы Мәхмәт Әмин Рәсүлзадәнең (Рәсүлзадә Мәхмәт Әмин (1884-1955) – күренекле азәрбайҗан дәүләт, сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе, журналист һәм язучы. 1922 елдан эмиграциядә төрле илләрдә яши, татар мөһаҗирләре белән якын элемтәдә тора) «23 июль, 1955, Әнкара» датасы куелган «Аркадашым Гаяз» исемле мәкаләсе килә. «Юл аркадашы» псевдонимы астында бирелгән язмада Г.Исхакыйның Мюнхенга ясаган сәяхәте, мөһаҗирлектәге рус булмаган халыкларның үзара мөнәсәбәтләре турында хәбәр ителә. «Мәрхүм Гаяз бәйне күреп-танышырга Аллаһ миңа насыйп итмәде» дип башлаган язманың авторы – Нью-Йорктан Хәмит Рәшит. Ул Г.Исхакыйны «ватанымда өмет чаткылары тудырган символ» дип атый, әсәрләренең совет хөкүмәте тарафыннан тыелуын, хәтта бу чорларда бик популярлашкан «Зәңгәр шәл» музыкаль комедиясен К.Тинчурин яза алмас, чөнки авыл тормышын бик белми, бу – мөгаен, Г.Исхакыйның эшедер дип, халык арасында тыярга омтылдылар, дигән кызык фикер дә китерә. «Икенче бөтендөнья сугышы мине дә, меңнәрчә Идел-Урал егетләре кебек, Германиягә чыгарып атты», дип үзе хакында да бераз мәгълүмат бирә автор [Milli Mücahit, 1955, s. 37– 38]. 70 яше тулу уңаеннан Г.Исхакыйга котлау хаты язып, соңыннан аның белән даими хәбәрләшү мөмкинлеге тапкан Х.Рәшит әдипнең сугыштан соң Германиядә калган бер төркем татарның АКШка күчәргә карар бирүен хуплавын да белдерә. «Истә тотам» исемле язманың авторы – ингуш халкының күренекле улы Вассан Гирәй Җабаги (Вассан Гирәй Җабаги (Джабагиев) (1882-1961) – ингуш халкының күренекле сәяси-иҗтимагый эшлеклесе, публицист, Европадагы Кавказ эмиграциясенең күренекле вәкиле. 1938 елдан соң Төркиядә яши) Г. Исхакый белән дүрт тапкыр очрашу-күрешүен, иң соңгысының Варшавада яшәгәндә шактый озак дәвам итүен, әдипнең аларда калуын, балаларына дин дәресе бирүен зур ихтирам хисләре белән искә ала. «Халкымның тәрбиячесе» исемле язманың авторы Һидаят Яшин (Һидаят Яшин (1894-1978) – педагог. Казанда туган, Укытучылар мәктәбендә укыган. Укуын бетермичә, фронтка алынган, Беренче бөтендөнья сугышында немецларга әсир төшкән. Соңрак Төркиягә килгән. 1915 елда Габдеррәшид Ибраһим һәм Галимҗан Идриси тәэсирендә төрек армиясенә кушылып, Месопотамия фронтында сугышкан. Сугыштан соң педагогик белемен арттырып, Артвин шәһәрендә эшләгән. Төркиядә тыелган «Яңа милли юл» журналын яшерен тарату эше белән шөгыльләнгән) Исхакыйның психология һәм педагогиканы яхшы белүенә басым ясый һәм милләтнең әхлагын яхшырту юнәлешендәге эшчәнлегенә, халкының бәйсез киләчәге өчен алып барган көрәшенә туктала. М. Вәли (Мостафа Вәли Айтуган (1907-1965), гаскәри һәм язучы. Алабуга шәһәренә якын авылларның берсендә туган. 1925-1928 елларда Казанда хәрби мәктәптә укыган, соңрак Мәскәүдә М. Фрунзе исемендәге хәрби академияне (1939-1941) бетергән. 1941 елда совет-фин сугышына майор буларак катнашкан, финнарга әсир төшкәч, Германиягә киткән һәм үз теләге белән Идел-Урал» легионына кергән (1943–1945), татарча газета чыгару эшенә өлеш керткән. Сугыштан соң Мюнхенда яшәгән, 1953 елда Идел-Урал милли мәркәзенең Германиядәге вәкиле булган,



● «Идел-Урал» журналының 1 сан тышлыгы.

● «Идел-Урал» журналының 1 санына кушымта.

ЖУРНАЛЫ (1955)

● «Идел-Урал» журналының 2 сан тышлыгы.

«Милли байрак» (1953-1954) газетасын оештырган, тик аның ике генә саны чыгып калган) имзасы астында басылган соңгы язмада Г.Исхакыйны күмү мәрасимендә катнашкан кешеләрнең сөйләгән сүзләре китерелә: Солтан Гариф, Ибраһим Бадай, төркестанлы Аман Бәрдимурат, азәрбайҗан Фатали-бәй, әрмән Тумасьян, калмык Шамба Балина (Шамба Балинов (псевдонимы Галдана) (1894-1959) – эмиграциядәге калмыкларның лидеры, журналист. Дондагы калмык кенәзе гаиләсеннән. Революциядән соң Берлинга күчеп киткән, 1928 елда калмык эмигрантлары оешмасы Khalmag Tanchin Tug ны нигезләгән. Эмиграциядәге күп кенә газета һәм журналларда язышкан. Бөек Ватан сугышы чорында Германиядә яшәгән. 1959 елда Америкада вафат булган), белорус Кабиш, украин Довгал, кырым татары И. Кырымәл (Мостафа Эдигәй Кырымәл (1911-1980) – кырым татарларының мөһаҗәрәттәге күренекле лидерларыннан берсе) һ.б. мәрхүм турында изгелек белән генә искә алганнар. Югарыда әйтелгәнчә, бу язмаларның барысы да «Идел-Урал» журналына кушымта итеп таратылган китапчыкта бирелгән.

Инде хәзер журналның үзендәге материалларга күз салыйк. Ни кызганыч, «Идел-Урал» бары тик ике генә сан чыгып калган, ни сәбәпле ябылган, төгәл билгеле түгел. Беренче сан 1955 елның 19 маенда – Төркиядә яшьлек һәм спорт бәйрәме буларак котлана торган һәм Ататөрекне искә алу көнендә чыкканга, тышлыкта Ататөрек һәйкәленең рәсеме урнаштырылган һәм «Ататөрек бары тик Анадолу төрекләренең түгел, бөтен төркиләрнең Атасы» дип язылган. Эчтәлеккә күз салу белән, журналның икe телдә: төрек һәм инглиз телләрендә чыгарырга планлаштырылганлыгы аңлашыла: сигез төрекчә язманың дүртесе инглизчәгә тәрҗемә итеп бирелгән. «Ни өчен чыга?» дип исемләнгән кереш мәкалә журналның оешуы һәм алга куйган максатлары хакында сөйли: дөньяда барган тарихи вакыйгалар эчендә Идел-Урал мәдәниятенең юкка чыгуына юл куймау, төрки халыкларның уртак мирасын, тарихын саклап калырга омтылу, И.Гаспралының «Телдә, фикердә, эштә берлек» шигаренә таянып эш итү, эмиграциядә яшәгән милләттәшләргә бу байлыкны таныту, аларга мәдәни һәм иҗтимагый ярдәм күрсәтү, чит илләргә таралган зыялыларыбыз белән элемтә урнаштыру. М.Сакмар тагын болай ди: «Шулай ук, төрек армиясенең элеккеге офицеры буларак, армиягә һәм ватаныма язуларым белән булса да, хезмәтемне дәвам иттерүне үземнең бурычым дип саныйм». Автор Идел-Урал буендагы сугышчылар турында да яңа материаллар бирергә омтылуын әйтә. «Идел-Урал» дип исемләнгән икенче мәкаләнең иясе М.С. дип кенә бирелсә дә, моның Мәҗит әфәнде үзе булганлыгы әллә ни шик тудырмый. Ул Идел, Җаек, Агыйдел елгалары турында гомуми белешмә бирә, хәтта татарча бер җырдан үрнәк тә китерә. Казан ханлыгы тарихы, рус кенәзлекләре белән мөнәсәбәтләрне истә тотып, алардан гыйбрәт алган хәлдә, хәзерге заманда Идел-Уралдан чыккан халыкларның үзара бердәмлеген ныгыту, матди-мәгънәви, мәдәни көчен арттыруның бик кирәкле булуын ассызыклый. Аннан соң шул ук М.С. имзасы белән «Казанның соңгы мәликәсе – сөелгән Сөем хан Бикә» исемле ике битлек шигырь урнаштырылган: Сөембикәнең гүзәллеге, ат өстендә ауга чыгулары, рус авына төшкән ире Җан Гали образы матур гына тасвирланган. Чираттагы язманың авторы – М. Сакмарның дусты генерал Пәртәв Дәмирхан (1878-1964), кайчандыр рус-япон сугышында инспектор-күзәтүче булып эшләгән, япон тарихы буенча хезмәтләр язган кеше. Ул язмасында Япония белән төрки халыклар арасындагы тугандашлык җепләре, ислам дине һәм япон культурасы арасындагы бәйләнешләр хакында сүз башлый, язма киләсе санда дәвам итәчәк, диелә. Япония темасын дәвам иттереп, М.Сакмар үзе дә «Япониядәге идел-ураллылар: дин һәм миллият» дигән темага материаллар китерә. Аннан соңгы язма «Совет Армиясендә сержантлар тәрбияләү мәсьәләсе» дип атала, авторы исемен күрсәтмичә, «Мөлтәче» (эмигрант) дип кенә куйган. Ике санда чыккан бу мәкаләдә яңа гына Совет Армиясенә алынган егетләрнең, нигездә, колхоз басуларында бертуктаусыз һәм авыр шартларда эшләп үскән авыл балалары булуын әйткәннән соң, колхозлардагы ниндиэшкә ничә эш көне (трудодень) язылуын җентекләп аңлата: сау-сәламәт ир-егет ел буена 250 эш көнена ия булса, колхоз рәисе исә, басуда эшләмәсә дә, 2250 эш көненә хуҗа дип, эш хакын түләүдәге тигезсезлеккә күрсәтә. Мирза Бала (Мирзабала Мәмәтзадә (1898-1959) – азәрбайҗан публицисты һәм язучысы. «Мусават» партиясенең рәисе (1955-1959). Европадагы азәрбайҗан эмиграциясенең күренекле вәкиле) үз мәкаләсендә Азәрбайҗан милли бәйсезлек хәрәкәтенең идеологы һәм лидеры Мәхмәт Әмин Рәсүлзадәнең 6 март көнне вафат булуын хәбәр итә һәм аның эшчәнлегенә кыскача анализ ясый. «Финляндиядәге Идел-Урал төркиләре» исемле язмада яңа чыккан басмаларга кыска гына күзәтү ясала. «Идел-Урал өлкәсенең җир асты байлыклары» исемле мәкаләдә бу төбәктә чыгарыла торган нефть ятмалары хакында мәгълүмат бирелә. Бу соңгы язмаларның да дәвамы киләсе саннарда чыгачагы хәбәр ителә.

Икенче санның тышлыгына Плевна каһарманы Гази Осман пашаның (1832-1900) портреты куелган. Беренче санда башланган П.Демирхан, М.Бала, «Мөлтәче» язмаларының дәвамы янында, бу санда иктибасларның (башка чыганаклардан алынып, тәрҗемә итеп бирелгән) язмаларның шактый булуы күзгә ташлана, мәсәлән, «Алтайлы кавемнәрнең язмышы», «Икенче Плевна сугышы», «Финляндия төркиләре», «Төрки казакълар хөрриятне ничек сайлады?», «Меото хәзәрләре» исемле язмалар башка илләрдә (нигездә, инглиз телендә) чыккан язмалардан алынган. Оригиналь әсәрләрдән бу санда игътибарга лаек язма – М.С. имзасы белән язылган «Идел-ураллы шәһит ителгән яшь шагыйрь Әхмәт Сима» исемле хәбәр һәм әлеге шәхеснең «Табынырдым» (Табына идем) исемле татарча шигыре. 1940 елның май аенда 23 яшендә үтерелгән Ә.Симанның соңгы шигыреннән берничә юлын без дә бирердә китерүне кирәк таптык:

Булган, диләр, татар гаскәренең
Тугай аты җирне таптаган,
Алтын Урда Урал тауларыннан
Карпатларга кадәр атлаган.
Ул дәвернең кешеләре, имеш,
Нык булганнар тимер-корычтан.
Урыс түгел, дөнья калтыраган
Кама бүрек, кыңгыр кылычтан.
Ул кавемнең дәһшәт чәчеп торган
Башкаласын Сарай дигәннәр,
Күп патшалар Татар ханнарына
Тез чүккәннәр, башын игәннәр...
Изге милләт, ике юл бар, сайла:
Я мәңгегә бетеп калырга,
Я яңадан кулыңа булат тотып,
Ирекне урыстан тартып алырга!
[İdil-Ural Kültür Mecmuası, № 2, s. 20]

Бу санда чыккан язмаларның бары тик икесе генә инглиз теленә тәрҗемә ителгән. Журналның башка саннары нигә чыкмаган? Әллә чыгып та, берәр рәсми тыюга дучар булганмы? Әлегә без бу хакта мәгълүмат таба алмадык. Ләкин өченче санга «дәвамы бар» дип язылган материалларның булуы, редакциянең басма эшен туктатырга җыенмавын күрсәтеп тора. Шул ук вакытта күпчелек материалны М.Сакмар әфәнденең үзе әзерләве аның янында якын фикердәшләре, көрәштәшләре аз яки бөтенләй булмавына ишарә итә кебек. Ничек кенә булмасын, әлеге басманың чит илләрдә яшәгән татар-башкорт мөһаҗирләренә, аларның балаларына туган халкыбызның тарихын һәм мәдәниятен таныту максатында оешкан булуы аңлашыла. «Идел-Урал» журналы чит илләрдәге татар вакытлы матбугатының бер парчасы булып санала ала һәм шул уңайдан җентекле өйрәнүгә лаек дип саныйм.

Әлфинә СИБГАТУЛЛИНА,
филология фәннәре докторы, профессор, Росссия Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.

«Фәнни Татарстан». 2022. № 2.

Айга карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

14 октябрь (шимбә). ***Рабигул әүвәл аеның 29 нчы көне. 30 нчы, 1 нче Ай тәүлекләре. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 6.14 сәгатьтә калка, 17.25 сәгатьтә бата. 20 сәгать 55 минуттан яңа Ай. Көн озынлыгы 10.37 сәгать.***

Тәүбә итү, гармониягә ирешү көне. Иҗат белән шөгыльләнү, айлык план төзү яхшы. Әйләнә-тирәне дә, үз хисләреңне дә кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек, интуиция арта. Баш һәм йөрәк зәгыйфь. Арып-талганчы эшләргә, артык кайнар ризык ашарга ярамый.

Баш авыртканда (1)

Кинәт баш авырта башласа, баш киемен салырга кирәк, бу кан тамырларына басымны киметә, аларга кислород яхшырак үтеп керә. Аннары 1 стакан җылы су эчү файдалы, ул кан тамырларын киңәйтәчәк, канны сыекландырачак. Авырту һаман кимемәсә, күзне йомып, тыныч кына ятып торырга кирәк. Аннары бармакларга, чигә һәм колакка массаж ясарга була. Болай да авырту басылмаса, түбәндәге киңәшләрнең берсен кулланып карарга туры киләчәк. Лимон йомшагын 2-3 минутка чигәләргә куеп тору, яки 1 стакан җылы суга 1 лимон согын сыгып эчү булышырга мөмкин. Атнасына 1 тапкыр булса да кәбестә согы эчү баш авыртуыннан саклый. Чигәгә 5-10 минутка кәбестә яфрагы куеп торырга да була.

15 октябрь (якшәмбе). ***Рабигул әүвәл аеның 30 нчы көне. 2 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 7.32 сәгатьтә калка, 17.31 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 10.32 сәгать.***

Яңа туган Ай Җир белән Кояш арасында, үзенең караңгы ягы белән Җиргә караган. Ай идарә итә торган һәрнәрсә – хисләр, кәеф, хәтер, кан басымы зәгыйфь. Кан басымы болай да түбән булган гипотониклар өчен бигрәк тә авыр вакыт. Бу чорда укуда уңышлар, тиз савыгу, югары эшчәнлеккә өметләнергә ярамый. Ашаганда талымлы булу хәерле. Аралашуны чикләү зарур.

Баш авыртканда (2)

Чирек стакан суга шулкадәр үк алма серкәсен кушып, шуны 1 минут суларга кирәк. Лимон яки бөтнек маен иснәргә дә була. Баш бик каты авыртканда, мәтрүшкә, бөтнек һәм кырлыган үләннәрен тигез микъдарда кушып, шуның 1 аш кашыгын термостагы ярты литр кайнар суда 30 минут төнәтәләр, 1 әр стакан эчәләр. Мелисса төнәтмәсе артык ярсыганда, арыганда, йөрәк тибеше еш айганда да булыша. 15 грамм вакланган үләнне 1 стакан кайнар суда 30 минут төнәтәләр, көненә 6 тапкыр 2 шәр аш кашыгы эчәләр. Яисә 1 аш кашыгы вакланган чабыр үләнен 1 стакан кайнар суда 30 минут төнәтәләр, сөзәләр, көненә 3 тапкыр 1 әр аш кашыгы эчәләр.

16 октябрь (дүшәмбе). ***Рабигул ахир аеның 1 нче көне. 3 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 8.56 сәгатьтә калка, 17.39 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 10.28 сәгать.***

Бик актив көн, хәвеф-хәтәр инстинкты, агрессия белән бәйле. Бүген чирләп китү ихтыяр көченең җитәрлек булмавын күрсәтә. Күзне арытмаска кирәк.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Баш авыртканда (3)

Баш даими авыртып интектерсә, андыз булыша. 1 аш кашыгы вакланган андыз үләнен 1 стакан кайнар суга салып, җылы урында 10 сәгать төнәтәләр, сөзәләр, көненә 4 тапкыр чирегешәр стакан эчәләр. Тигез микъдарда кушылган мәтрүшкә, сары мәтрүшкә, бөтнек үләннәренең 1 аш кашыгын 1 стакан кайнар суда төнәтеп, сөзәләр, 3 атна дәвамында көненә 1 тапкыр эчәләр. Балан яки кара карлыган согы эчү бик файдалы. Тигез микъдарда кушылган бал белән балан да баш авыртуны баса, 3 атна дәвамында көненә 4 тапкыр 1 әр аш кашыгы ашарга кирәк. Чигәгә чи бәрәңге телеме яки кабыгы белән пешерелгән бәрәңге куеп тору, сарымсак согы сөртү дә баш авыртуны баса ала.

17 октябрь (сишәмбе). ***Рабигул ахир аеның 2 нче көне. 11 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 10.24 сәгатьтә калка, 17.52 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 10.23 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Теләсә нинди элемтә, танышулар, күмәк эш бүген кыен кичерелә. Озаграк йоклау хәерле. Тәмлерәк һәм күбрәк ашау теләге зур булса да, чаманы югалтмаска кирәк. Ач торырга ярамый.

18 октябрь (чәршәмбе). ***Рабигул ахир аеның 3 нче көне. 5 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 11.55 сәгатьтә калка, 18.13 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 10.19 сәгать.***

Бүген юлда булу әйбәт. Ач тору тыела. Күңел нәрсә тели, күпме тели – шулкадәр ашарга була, бигрәк тә яшелчә файдалы. Башлаган эшне ахырына җиткезү зарур. Ашказаны-эчәк авырулары кискенләшү тискәре энергиянең артык күп тупланууын күрсәтә. Кан әйләнеше системасы, ияк, муен, бронхлар зәгыйфь.

19 октябрь (пәнҗешәмбе). ***Рабигул ахир аеның 4 нче көне. 6 нчы Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 13.21 сәгатьтә калка, 18.48 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 10.15 сәгать.***

Хисчәнлек арта. Һәртөрле аралашу күңелгә ятышлы. Бу көннәрдә әти-әнигә ихтирам көче аеруча куәтләнә, гаиләдә бергә җыелып, балачакның күңелле хатирәләрен яңарту яшәү көче өсти. Бизләр системасы, җилкә, кул, үпкә, бронхлар зәгыйфь, салкын тию ихтималы зур.

20 октябрь (җомга). ***Рабигул ахир аеның 5 нче көне. 7 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 14.30 сәгатьтә калка, 19.47 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 10.10 сәгать.***

Һава энергиясенә бәйле көн. Тынгысызланырга, гайбәт сөйләргә ярамый. Ялгыз калып уйлану файдалы. Нерв системасы, үпкә зәгыйфь. Ач тору, ашказанын һәм эчәклекне чистарту уңай нәтиҗә бирә.

Татлы катлама

5 йомырка, 1 әр стакан он һәм шикәр, берәр чеметем тоз һәм ваниль, 200 грамм варенье, джем яки куертылган сөт кирәк. Йомырканы шикәр белән куерганчы күпертәләр, экренләп он өстиләр. Камырны пергамент кәгазе җәелгән табага агызып, 180-190 градуслы газ мичендә 10-15 минут пешерәләр. Кәгазен куптарып, кайнар бисквитны сөлгегә урыйлар. Суынгач, кире сүтәләр, җем, варенье яки куертылган сөт сылап, рулет итеп төрәләр, өстенә шикәр оны сибәләр.

Бесландагы

Бесландагы фаҗигага – 19 ел. Шул көннән алып ул – кайгы шәһәре, үз балаларын кочаклый алмаячак ана куллары, аталарның оялмыйча агызган күз яшьләре шәһәре.

Әлеге фаҗига Бесландагы һәр кешегә кагыла.

3 көн дәвамында җәһәннәмдә булган тоткыннарның һәм аларның якыннарының хәтерләрендә уелып калган бу кичерешләр еллар узу белән сүрелми. Алар, бу фаҗига корбаннарын онытып булмый һәм ярамый да, дип сөйли. 186 сы бала булган 333 кешенең җаннары спорт залы диварлары эчендә кала. Әлеге фаҗига шаһитләре, бу беркайчан да кабатланмаска тиеш, ди.

Үлгәннәр рухы

«Кызлар, мәктәпкә барырга вакыт! Мин сезнең энегезне җыям да, аннан...» – дип ашыктыра кызларын Эльза Цабиева. Аның шатлыклы көне: олы кызы Алана 5нче сыйныфка, ә кечесе, Зәлинә, 3нче сыйныфка бара. Алар ашыга-ашыга җиенса да, линейкага бераз соңга калалар. Һәрберсе үз сыйныфы янына баса, ә 3 минуттан соң әсирлеккә алу башлана…

«Спорт залында һәр җирдә бомбалар эленеп тора иде, йөзләгән кеше, кысан, – дип сөйли «СтарХит»ка Зәлинә Плиева. – Егылып яткан җиремнән кузгалмадым да. Кичкә таба гына күршеләремнең берсе минем кайда булуымны сеңлемә әйтте. Алана минем яныма килә алды. Без 3 көн буе бер-беребезне җибәрмәдек, ашамадык, бу куркыныч сәгатьләрдә иң зур хәзинә булган бер-ике тамчы су йоттык. Штурм вакытында без инде бөтенләй хәлсез идек. Террорчылар, ыгы-зыгыга бирелеп, газ битлекләрен киделәр, һәм шартлау тавышы ишетелде. Көчле шартлау, һәм барысы да төрле якка очты. Мин дә кимендә 4 метрга очтым. Апамны бүтән исән килеш күрмәдем...»

Азат ителгән көнне, 3 сентябрьдә, Зәлинә өстенә түшәмнең бер өлеше җимерелеп төшә. «Мин аңымны югалттым, – дип сөйли кыз. – Аңыма килгәч тә тора алмадым, тирә-якта үлгән кешеләр иде. Тагын 15 минутлап яттым һәм кинәт кенә террористны күрдем, куркып калдым һәм үлгән булып кыландым. Аннары ул юкка чыкты. Аякларымны селкеттем, шунда мине волонтерлар күреп алды, җимерекләр арасыннан алып чыгып, носилкага салдылар. Әлегә кадәр күз алдымда тора: бер табиб, ә аның янында – 30лап кеше. «Аны ал, ул үлә!» – дип кычкыралар. «Юк, минем баламны ал», – ди икенчесе. Ләкин доктор миңа карады да, тотып алып, операция бүлмәсенә җибәрде. Мин инде бүлмәдә уяндым, җәрәхәтләрем барлыгын, ә аннары апамның мине бүтән беркайчан да кулымнан тотып тормаячагын белдем».

Алана Цабиева Бесландагы фәрештәләренең берсе була. «Аллага шөкер, әни безнең белән барырга өлгермәде, – ди Зәлинә. – Кайвакыт әти-әниемнең ничек исән калуына гаҗәпләнәм. 1 яшьлек энебез өчен бөтен гаилә үз-үзен кулда тоткандыр. Кайвакыт әти-әниләр үзләрен гаепли: ни өчен җибәрдек, ни өчен ярдәм итмәдек, диләр. Туганнар сәламәт, барысы да яхшы. Ничек яхшы? Мәктәп янында яшибез, тәрәзәләр спорт залына карап тора. Монда – үле тынлык. Безнең подъездан гына да 8 бала өйгә кайтмады».

Зәлинә апасының үз гаиләсен саклавына ышана. «Ул бер тапкыр төшкә керде, – дип искә ала ул. – Аны борчымавыбызны сорады – әти-әнием һәр көнне, вахтадагы кебек, зиратка бара иде. Тыңладык, кабергә сирәгрәк йөри башладык. Мин әниемнән: «Без кая да булса күченә алыр идекме?» – дип сорадым. Ә ул: «Әгәр Алана исән булса, монда бер көн дә калмас идек!» – диде. Кеше бар нәрсәгә күнегә: яралар төзәлә, әмма җәрәхәт эзләре кала. Мин беркайчан да бернәрсәне дә онытмаячакмын һәм теләмим дә, без истә тотарга тиеш! Фаҗигага багышланган гыйбадәтханәне төзеп бетерүләрен көтәм, анда кереп, шәм куячакмын. Минемчә, анда үлгән балаларның рухлары яшәячәк, алар арасында минем Аланочкам да…»

● **Алана (сулда) иртән линейка алдыннан өйдә брошкасын онытып калдыра. Хәзер ул гаилә реликвиясе булып тора.**

Янәшәдә улы

Боевиклар мәктәпне басып алганда, Таймураз Царахов бәйрәм салюты аттылар дип уйлаган. Аннары кычкырулар, атулар ишетә... Һәм шунда гына бәла килүен аңлап ала. Тоткыннар арасында аның балалары – 12 яшьлек Эльбрус һәм 9 яшьлек Виктория да була.

«Гадәттәгечә, кызым һәм улым, киенеп, линейкага китте, – дип сөйли «Стархит»ка ир-ат. «Безгә бүген тагын музыка мәктәбенә дә линейкага барырга кирәк, – дип сөйләнделәр», – дип искә ала ул. Виканың үз сыйныфы янында басып торуын, «әнием һәм әтием янына барырга телим» дип кыбырсынуын хәтерли. Ә Эльбрус аны: «Ник елыйсың?» – дип тынычландыра. Тагын ул, улымның залда дустына утып бирүен сөйләде, иптәшенә: «Әгәр дә безне чыгарсалар, мин сине уятырмын!» – дип вәгъдә иткән. Ул үзе тәрәзә янында басып торган, бомба астында, мөгаен, минем улымны беренчеләрдән булып дулкын каплагандыр да. Ә ул малай бер җәрәхәтсез чыкты. Кызым ничек котылган? Бер хатын-кыз ярдәм иткән – аны тәрәзәдән этеп чыгарган! Әлегә кадәр без аның кем икәнен белмибез».

Боевиклар юк ителгәннән соң, кайгыга баткан әти кеше үз балаларын эзли башлый. «Кызымны кыйпылчык яралары белән Владикавказга җибәрделәр, – дип уртаклаша Таймураз. – Күршеләрнең берсе улымны күрүен әйтте, аңа

фаҗига онытылмымый

Бесланда 1 нче мәктәптәге линейкадан 334 кеше өенә кире кайтмый, шуларның 186сы – балалар. Фото: P.Domain, commons.wikimedia.org

операция ясыйлар, диде. Берничә тапкыр медицина хезмәткәрләреннән: «Аның белән барысы да яхшымы?» – дип сорагач, мине тынычландырдылар: «Куркыныч юк!» – диделәр. Ләкин табиб өстәлендәге бала минем улым түгел булып чыкты… Аны 1 ай эзләдем: Мәскәүдә дә, Ростов-Донда да, ахырга кадәр баламның юклыгына ышанырга теләмәдем. Улымны исән килеш табам, дип кабатладым. Ләкин ДНК өмет юклыгын күрсәтте».

Фаҗигадән соң 2 ел үткәч, Цараховлар гаиләсенә яңа бәла килә. «Хатыным улыбызның аны күккә чакыруы турында уйлана башлады. Һәм шулай булды да. Юл аркылы чыкканда, аны машина бәрдерде. Аны Эльбрустан ерак түгел урында җирләдек. Мин улымны сизәмме? Кайвакыт әйе кебек тоела, ләкин андый хәл була алмый, ничек... Ул бит инде берничә ел дәвамында юк».

Таймураз, күп ата-аналардан аермалы буларак, алга таба яшәү өчен көч таба. «Эшлим, – дип сөйли ул. – Канадага яки Швейцариягә күченү мөмкинлегем бар иде, ләкин китмәдем».

Чиста биттән

«Бердәнбер балаңны югалту һәм шуның белән яшәү – бу чын җәһәннәм. Мин үзем дә үлдем. Вөҗдан газабы, зиратта сәгатьләр уздыру, үз-үзеңне бетерү. Вакыт дәвалармый», – дип уртаклаша Лариса Сокаева.

1 сентябрьдә ул кызы һәм башкалар белән бергә тоткынлыкка алына. Альбина әнисен кысып кочаклап ала. Ә олыларга эчәргә рөхсәт ителмәгәч, кыз авызына су җыеп, әнисенә бирер өчен, аның иреннәренә кагыла... Быел әлеге кечкенә, әмма көчле балага 31 яшь тулган булыр иде.

«Ул ачык, һәрвакыт елмаеп торучан булып истә калды, – дип сөйли «СтарХит»ка аның туганы Ацамаз Сокаев. – Террор һөҗүменнән соң Альбинаның әнисе берничә ел стеллаждан уенчыкларны алмады. «Ни өчен?!» – диде. Беркем берни әйтмәде... Минем этием сеңлемнең әтисе белән бергә аларның гәүдәләрен танырга барды. Коточкыч! Балаларны тәреләр, йөзекләр, беләзекләр буенча таныганнар... Альбинаны да шулай тапканнар».

Быел кызга 31 яшь тулган булыр иде.

Кыз, мөгаен, гаиләне саклаучы фәрештәгә әйләнгәндер. 2006 елда Владимир һәм Лариса Сокаевларның улы туа. Аңа Альбинага мәктәптә ошаган малай хөрмәтенә Георгий дип исем кушалар. «Аңа еш кына апасы турында сөйлиләр, – ди Ацамаз. – Малай эти-әнисенә көч бирде».

Аның артында мин үземне таш дивар артындагы кебек хис итә идем.

Александр Озиев әлеге датаны һәр ел саен елап каршы ала. Ул моннан оялмый, чөнки фаҗига аның кадерле кешеләрен – туганнан туган абыйсын һәм апасын алып киткән.

Саша бигрәк тә абыйсы Вадимны сагына. Балачакларын алар бер ишегалдында үткәргән. Дөрес, төрле мәктәпләрдә укыганнар. «Ул көнне мин бәйрәмдә идем һәм теракт турында хәбәрне ишеткәч, дөресен генә әйткәндә, моңа әһәмият бирмәдем. Чөнки ул вакытта без үлемнең нәрсә икәнен аңламый идек, ә соңыннан ул һәр йөртка керде, – дип сөйли Александр. – Мондый вакыйгадан соң Аллаһка ышанудан туктыйсың. Балалар, мондый коточкыч хәлләрне кичерер өчен, шуның кадәр гөнаһ кыла алган була алмый. Хәзер мин атеист».

Александр илаһи көчләргә ышанмаса да, аларның гаиләсендә могҗиза булган. Берникадәр вакыттан соң аның абыйсы, Вадимның әтисе Сергей, терактка эләгә... һәм исән кала. «Ул Владикавказ базарында миналы машина янында торган була, – дип сөйли Александр. – Шартлаудан соң, ул җилкәсенә туңдырма чәчрәгән дип уйлый, ә бу кемнеңдер баш мие булып чыга. Табиблар тиз арада абыйны хастаханәгә алып китәләр, ул вакытта аның колаклары ишетми, күзләре күрми башлый, хәзер ишетүе дә, күрүе дә кире кайтты».

Озиевлар гаиләсендә Беслан фаҗигасе турында сөйләшмәскә тырышалар. «Вадим нинди игелекле булган, дип уйлыйм, аның артында мин үземне таш дивар артындагы кебек хис итә идем, – дип сөйли Саша. – Мин андый кешеләрне бүтән очратмадым. Әнисенең заводтан кайтуын хәтерлим, ул шунда ук аның янына килә дә: «Арыдыңмы? Берәр җирең авыртмыймы?» – дип сорый иде. Вадимның энесе Володя калды. Ул тырыша, эшли, ә абыем өйдә утыра... Шул сентябрь аеннан соң Осетиядә дөньядан йөз чөергән кешеләр санап бетергесез».

Беслан әнисе

Һәлак булганнарның алфавит исемлегендә 115 нче урында 9 яшьлек Алана Доган саналa. Ул әнисе һәм 1 яшьлек сеңлесе Милена белән бергә шул агач идәндә боевиклар әсирлегендә була. «Автомат тавышлары ишетелгәч, без Алана белән паникага бирелеп бер-беребезне югалттык, – дип сөйли Анета Гадиева. – Мине залга соңгы булып алып керделәр. Бер генә уй бар иде: «Кызым кайда?» Кинәт укытучы: «Анета, ул монда!» – дип кычкырды. Мине күргәч, Алана елый башлады: «Монда килмә, сине атып үтерәчәкләр!» – диде, ә үзе кешеләр аша минем яныма шуышты. Мин аны кочакладым, куркуым бераз бетте. Милена эсседән, ачлыктан һәм сусаудан елады. Ул миңа елышты. Шулай итеп без 1 тәүлек буе почмакта утырдык».

Икенче көнне, террорчылар белән сөйләшүләр алып бару өчен, мәктәпкә Ингушетиянең элекке президенты Руслан Аушевны керттеләр. Ул күкрәк балалары белән аналарны азат итәчәкләр, дип килеште. «Баланы олы кызым алып китсен, дип сорадым, мине аның урынына калдырулары өчен ялвардым, – дип искә ала Анета. – Ләкин беркем дә тыңламады... Без Мила белән исән калдык, ә Алана...»

Коткарып кала алмаган кызы истәлегенә Анета «Беслан әниләре» комитеты рәистәше була. «Мин әле дә 2004 елның 2 сентябрендәге кебек, – ди ул. – Онытылырга телисең, ләкин булмый. Йөрисең, нәрсәдер эшлисең, аннары кабат әйләнеп кайткан сыман. Без тикшерү процессын активлаштырырга тырышабыз, чөнки эш әлегә кадәр ачылмаган. Безнең бурыч – дәшми калмау, фаҗигане сөртеп атырга юл куймау! Без барлык корбаннарга ярдәм итәбез. Сәламәтлеге бозылган кешеләргә сәяхәтләр оештырабыз, аларга ташламалар ясыйбыз...»

Бу ханым авыр эштә аңа һәлак булган кызы ярдәм итә, дип ышана. «Җирдәге хыяллар турында сөйләсәк, Миленага бәла-казалар килмәсен, ул үзен ышанычлы хис итсен һәм тормышны яратсын дип телим, – ди безнең героиня. – Күк хыяллары да бар – Алана белән очрашуны, ике дөньяның берләшүен телим...»

Ел саен меңләгән кеше үз фәрештәләрен искә алу өчен җыела.

Александр НОВО.

Starhit.ru сайтыннан тәрҗемә ителде.

Фотолар https://www.starhit.ru/ сайтыннан.

intertat.tatar.

Мәдәни җомга
13 октябрь
№40, 2023

Сарымсак кына димә

Япониянең бер төркем галиме, катлаулы сынаулар үткәреп, әлегәчә фәнгә билгеле булмаган фактларны ачыклаган. Алар барыбызга да таныш яшелчә – вирусларга каршы тору үзлеге өчен халыкта бик югары бәяләнгән сарымсакны җентекләп өйрәнгән. Сынау вакытында галимнәр баш миләрендә яман шеш булган тычканнарга берничә ай буе сарымсак ашаткан һәм гаҗәеп ачыш ясаган – шеш күзәнәкләре берничә тапкыр кимегән. Димәк, гап-гади сарымсак кешенең баш миендәге яман шеш күзәнәкләрен дә юкка чыгарырга сәләтле. Әлеге юнәлештә эш дәвам итә, һәм галимнәр якын киләчәктә онкологиягә каршы торырлык дару ниһаять уйлап табылыр, дип өметләнә.

(“Fishki.net”).

Теле барның юлы бар

Америкадагы Чикаго университеты галимнәре күптелле даирәнең баланың аралашу күнекмәләренә уңай йогынты ясавында тагын бер тапкыр инанган. Сабыйга әлеге телләрнең барысын да белү мәҗбүри түгел, аларны гел ишетү дә җитә икән. Яңа тикшеренүдә 4-6 яшьлек 75 бала катнашкан. Аларның социаль аралашу дәрәҗәсен бәяләү максатыннан үткәрелгән тест күптелле мохиттә үсүче сабыйларның биремнәрне яхшырак аңлап эшләвен күрсәткән. Белгечләр фикеренчә, чит телдә сөйләшүне ешрак ишеткән балага башка кеше сүзенең мәгънәсенә төшенү ансатрак. Моннан тыш, икенче бер тикшеренү нәтиҗәләре ике телдә сөйләшкән баланың дөньяны башкачарак күзаллавын күрсәткән. Андый балалар, һәрнәрсәгә өйрәнеп була, дип уйлый, бер генә телдә сөйләшкәннәре исә, бар нәрсә дә тумыштан гына бирелә, дип саный. Галимнәр фикеренчә, балачакта икенче тел өйрәнү стереотиплар формалашуга юл куймый.

(“The Mirror”).

Пуля барыбер эзләп тапкан

1883 елда Генри Зигланд үзенең сөйгәнен ташлаган, бичара кыз шул кайгыдан үзенә кул салган. Сеңлесенең үлемендә Генрины гаепләп, абыйсы аның башына пистолеттан аткан, аннары үзенең чигәсенә аткан да, шундук үлгән. Ә пуля Зигландның битен тырнап кына үткән дә, ишегалдындагы агачка кереп киткән. Берничә елдан соң Генри агачны төпләргә уйлаган, көче җитмәгәч, астына динамит куеп шартлаткан. Агач эчендәге теге пуля очып чыгып, Генриның башына килеп кергән дә, үтергән. Шул рәвешле Зигланд язмышыннан барыбер кача алмаган.

(“Die Presse”).



Барбиның “әнисе”

Планетада иң популяр курчакны уйлап табучы Рут Москович яһүд гаиләсендә унынчы бала булып дөньяга килгән. Польшадан АКШка килеп урнашкан әти-әнисе кызларының бай кеше белән гаилә коруын теләгән, шунлыктан аның сәнгать дизайны колледжына керүен бер дә өнәмәгән. 1938 елда Рут картиналар өчен декоратив рамнар ясау остасы Эллиот Хэндлерга кияүгә чыккан, бер-бер артлы кызлары Барбара, уллары Кеннет туган. Бервакыт кызының әтисеннән калган агач шакмаклардан курчакларына карават ясап уйнавын күзәткән Рут иренә уенчык җиһазлар ясап карарга тәкъдим иткән. Көтмәгәндә бу уенчык җиһазлар рам сатудан күбрәк табыш китерә башлаган. Бизнесны үстерү өчен акча кирәккәч, Хэндлер дусты Харольд Матсон белән капиталын берләштергән һәм “Mattel” компаниясенә нигез салган. 1956 елда Швейцариядә ял иткәндә Рут озын аяклы, калку күкрәкле сәер курчак күреп алган. Немец комикслары мотивлары буенча Р.Хойзер ясаган Лилли исемле сувенир курчак өлкәннәргә тәгаенләнгән һәм барларда сатылган. Рут ирен Лилли курчагы образына хокукны сатып алуга күндергән. 1957 елдан “Mattel” компаниясе курчакны җитештерә дә башлаган. Рут яңа курчакны ул елларда гаять популяр Джейн Мэнсфилд сынына охшатып ясаган, әлеге актриса үзенең йортын ал төстәге җиһазлар белән тулы курчак йортына әйләндергән. Рут Хэндлер да курчаклары өчен шундый йортлар ясаткан. 1958 елда ул үз уенчыгына патент алган һәм аңа Барби дип кызының исемен кушкан. Тик ата-аналар курчакның тышкы кыяфәтен бик вульгар дип тапкан һәм аны сатып алудан баш тарткан. Рут исә аптырап калмаган, телевидениедә реклама биргән. Берничә йөз мең курчак тиз арада сатылып беткән. Беренче ун елда Барбиның “әнисе” ярты миллиард доллар акча эшләгән, ул Американың иң танылган эшкуар хатын-кызына әйләнгән. 1970 елда Рут Хэндлерның күкрәгендә яман шеш табылган, операциядән соң ул инде компания президенты булып кәгазьдә генә саналган. 1978 елда исә аны, кыйммәтле кәгазьләр белән махинацияләрдә гаепләп, 5 елга шартлы рәвештә ирегеннән мәхрүм иткәннәр һәм бик зур штраф түләткәннәр. Гаммәви мәгълүмат чаралары аңа каршы кампания башланган. Әмма Рут Хэндлер төшенкелеккә бирелмәгән: мастоэктомиядән соң күкрәксез калучылар өчен протез җитештерүне җайга салган. 1991 елда үз компаниясен медицина корпорациясенә саткан. Шул елда улы Кеннет вафат булган, ә кызы әнисен үзенә тиешле игътибар бирмәүдә гаепләп чыккан. Рут Хэндлер 2002 елда 85 яшендә бакыйлыкка күчкән. 1993 елда Барби курчагы гаиләгә миллиард доллар, 1994 елда инде ике миллиард доллар акча китергән. Хәзер ул дөньяның 150 илендә 25-70 долларга сатыла һәм җиһанда иң күп сатыла торган егерме товар исемлегенә керә.

(“Bloomberg”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

16 октябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «КАЙДА СИН?» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30, 16.00 «Халкым минем...» 12+
12.00, 22.10 «ТУЗГАН ТОРАКТАН КҮЧКӘНДӘ». 16+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Акыл батл» һәм «Учимся вместе». 16+
17.30 «Ватандашлар». 16+
18.00 «Кто мы татары?» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 12+
21.00 «Заман көзгесе». 6+
23.00 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
0.00 «Соотечественники». 16+
0.25 «Каравай». 6+
0.50 «Путь». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05 «Йөрәктән - йөрәккә». Илтөзәр Мөхәммәтгалиев турында телеочерк. 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30 «Заман көзгесе». 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы». 6+
19.10, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
20.30 «Таяну ноктасы». 16+
21.25 «Калеб». 6+
